

## Балтачта купьеллык бәрәңге үстерәләр?!

«Күршебез Камилнең бакчада эшләгәнен күреп, үземә дә бераз ял булыр дип, койма буена килсәм, ни күрим... бәрәңге казып ята! Календарьда 1 май ләбаса! Ник берсе өшесен, бәрәңгеләр артык зур булмасалар да, тавык йомыркасы кадәрлеләре күренгәли.»

8 БИТ



## Тормышмы бу?

Сугыш ветераны Габдеразак бабай: «Картаймыш көнемдә үзем салган йортка үзем хуҗа була алмыйм», – ди.

7 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

**Пәнҗешәмбе** | 5.05.2016 | № 47 (5665)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

# «Сугышны урамда малайлар сугышкан кебек күз алдына китерә идек»

**«Сугышны без баштарак урамда малайлар сугышкан кебек кенә күз алдына китерә идек. Һәр көнне авылдан ирләр сугышка чыгып китә башлагач кына, аның хәтәр нәрсә икәнен аңлый башладык. Бертуган абыем да китте, апамны ФЗӨгә җибәрделәр», – ди Мөнәвәрә Галиева.**

5 БИТ





«Лампочка янмаса да, Президентка язалар»

4 БИТ



«ШК» журналисты белән бавырсак пешерергә өйрәнәбез

9 БИТ

## РЕСПУБЛИКАДА

### КУКМАРА

Табигатьне саклау һәм урманнарга сакчыл караш тәрбияләү максатыннан, 14 май көнне Кукмарада традицион рәвештә Урман утырту көне узачак.

### ТҮБӘН КАМА

9 майда, Бөек Җиңү бәйрәме уңаеннан, Түбән Камада яшәүче күп балалы гаиләләр Лемаев мәйданында сугыш ветераннарын искә алачак. Бу көнне күккә йөзләгән ак шар очырырга җыеналар. Чарада катнашырга теләгән кешегә дә таләп бер – гель белән тутырылган ак шар алып килергә кирәк.

### АЛЕКСЕЕВСК

Алексеевскида икенче мәктәп мәйданында мини-футбол өчен корт ясыйлар. Җәй көне бирегә тренажерлар урнаштырырга да уйлыйлар.

### АЛАБУГА

Быел Алабугада 80 меңләп чәчәк утыртырга җыеналар. Калага барысы 24 сорттагы чәчәк ямь бирәчәк. Бизәү өчен төргәкле газон һәм ылыслы куаклар кулланылачак.

### БАЛЫК БИСТӘСЕ

Татарстанның кайбер районнарында май бәйрәмнәре йомырка җыю белән истә кала. Пасхага бернинди катнашы булмаган әлеге гореф-гадәт Балык Бистәсендә дә электән сакланып калган. Авыл халкы иртә белән үк йомыркаларны буяп, тәм-томнарын пешереп куя. Балалар исә өйдән-өйгә кереп, йомырка, күчтәнәч җыя.

### МЕНДЕЛЕЕВСК

Менделеевскида «Кәләшләр мәктәбе» эшли башлаган. Анда өйләнешергә теләгән яшьләр үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап таба ала. Шулай ук төрле ярышлар да уза. Әйтик, ун пар арасында Динара Юзикиева һәм Турал Әхмәдов туй оештыруга сертификат отканнар.

**Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.**

# Ярдәмнән бигрәк, аралашу кирәк

**«Ветераннар исән чакта алар белән мөмкин кадәр күбрәк аралашырга, сугыш истәлекләрен сорашып калырга кирәк, бу – республикабыз хөкүмәтенең дә төп бурычы. Дөнья куабыз, еш кына ветераннарның балалары да әтиәниләре белән сөйләшергә вакыт тапмый. Ә тыл һәм сугыш ветераннары бүген социаль ярдәмнән бигрәк, аралашуга мохтаҗ. Бер ел эчендә 11 меңнән артык ветеран һәм сугышта катнашканнарның тол хатыннарын югалттык, исәннәрнең кадерен белик», – диде кичә Татарстан премьер-министр урынбасары Васил Шәйхразиев журналистлар белән очрашуда. Ул сугыш шартларында эшләгән журналистларның батырлыкларын да искәртеп узды.**

Эльвира МОЗАФФАР


Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Бөек Ватан сугышында катнашкан ветеран һәм сугыш инвалидлары бүген 2671 кеше. Аларның иң яшь дигәненә дә 83 тирәсе. Сугыш авырлыкларын, ачлык, ялангачлыкны үз җилкәләрендә татысалар да, өлкән буынның ныклыгына сокланырлык, күбесе актив тормыш алып бара. Татарстанның Министрлар кабинетында Бөек Җиңүнең 71 еллыгына чараларга әзерлек уңаеннан уздырылган конференциядә республикада бердәнбер исән Советлар Союзы Герое Борис Кузнецов та катнашты. Сөбханалла, Борис аганың яшәү дәрте ташып тора. Россия күләмендә узган чараларда гел Татарстан данын яклый. 16 яшеннән үзе теләп сугышка китүен, Берлинны алуда катнашуын бик ялкынланып сөйләде ул, барлык татарстанлыларны Җиңү бәйрәме белән котлады.

Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова сугыш һәм тыл ветераннарына социаль ярдәм күрсәтү турында сөйләде. Социаль хезмәткәрләр республикада 4 меңнән артык ветеран һәм тыл хезмәтчәннәренең өйләренә килеп булыша. Быелның маеннан, авылларда ялгыз яшәүче сугыш хезмәтчәннәренә дә бушлай ярдәм күрсәтеләчәк. Татарстанда 113 сугыш һәм тыл ветеранының торагына капиталь төзекләндерү ясыйсы бар.

Җиңү көне уңаеннан, мөһим чаралар оештырырга җыеналар. Әйтик, «Җиңү урманы» акциясе кысаларында, һәр ветеран хөрмәтенә, исемен язып, агач утырту каралган. Җиңү паркында сугышта һәлак булган батырлар истәлегенә чәчәкләр салачаклар. Иртәгә 6 май көнне 13.00 сәгатьтә Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында Шамил Фәрхетдинов пьесасы буенча сәхнәләштерелгән «Алтын көз» хәйрия спектакле күрсәтеләчәк. Бу көнне театр 300ләп сугыш һәм тыл ветеранын бергә җыяр дип көтелә. Бәйрәм көннәрендә аеруча да бер генә ветеран, тыл хезмәтчәне дә үзен ялгыз хис итмәсен, хөрмәт тойсын. Бәйрәмнең төп чарасы Ирек мәйданында узачак. Бу урынны юкка гына сайламаганнар. 1945 елда Бөек Җиңүне нәкъ менә биредә каршылаганнар. Сугыш истәлекләрен үзендә саклаган бу мәйданда сәгать унда бәйрәм башланачак.

Сәгать 18.00дә «Казан-Арена» стадионында башланган концерт программасы кичкә кадәр дәвам итәчәк. Бәйрәм чаралары 22.00дә салют белән тәгәлләнәчәк. Бәйрәм фейерверкын күзәтү өчен иң уңайлы урыннар Казансу буе һәм «Казан-Арена» стадионы каршындагы мәйдан, ди оештыручылар. Җәмәгать транспорты 9 Май көнне төнгә кадәр эшләячәк.

**Теманың дәвамы 5 нче биттә**

## Шәһәр кәефе



**ЛОТФУЛЛА ГАЛИУЛЛИН,**
пенсионер:

– Лаеш районындагы Татар Янтыгы авылыннан уналты яшемдә килдем Казанга. Телевышка төзелешендә катнаштым, 1956 нчы ел иде ул. «Оргсинтез» заводы төзелешендә эшләдем. Сазлыкка балчык түшәлде. Ир-атлар белән бергә хатын-кызлар да билдән су ерып хезмәт куйды анда. Кыш сазлыкта су каткач, боз өстеннән йөрдек. Кайбер урыннарда боз ватылып китә дә, эшчеләр билдән суга бата иде. Шунда аякларга салкын тиеп калган, ахрысы.



**ЛИЛИЯ ӘХМӘТОВА,**
журналист:

– Бөек Җиңү бәйрәме белән рухланып йөрим. «Үлемсез полк» акциясен бик хуплыйм. Ватанпәрвәрлек хисләрен кузгатучы, үстерүче һәм ныгытучы чара ул. Ерак сәфәрләр планлаштырган юк быел. Җәйге ялда Аксубай районы Яңа Үзи авылында яшәүче әти-әниебез янына кайтачакбыз. Аллага шөкер, әти-әниләр исәнсау. Авырмасыннар, туганнарың булу бик рәхәт.



**РУЗАЛИЯ АРСЛАНОВА,**
пенсионер:

– Казанда 1938 елда туганмын. Ашарга сорап, каты елаганмын. «Юк шул, булса, бер бөтен ипи асып куяр идем муенына», – дип, әнием Оркыя мине кочаклап елаган. Сугыш елларында ачлык та күпме кешеләрне кырды бит. Кечкенә булсам да, Җиңү хәбәре килгән көнне ачык хәтерлим. Багана башларындагы радиолардан көчле музыка агылды. Урамнар халыкка тулды, елаша-елаша кочаклаштылар. Гармунчылар уйнаган түгәрәкләрдә бөтен кеше биеде.



**ӘМИНӘ КАЮМОВА,**
пенсионер:

– Сугыш елы баласы мин, 1944 елда Казанда дөньяга килгәнмен. Әти үзен хәрби комиссариаттан борып кайтарганнарына үртәлеп сөйли торган иде. Аның ике кулы да гарип иде. «Алмадылар, сугышка барсам, фашистны ничек тә тукмар идем әле», – дип сөйли иде. Бүгенге тормышларыбыз Ходайга шөкер! Сугыштан соңгы елларда олы бәйрәмнәр алдыннан әйбер бәяләре гел төшә иде.



**БУЛАТ МӨХӘРЛӘМОВ,**
студент:

– Дәү әтиемнең әтисе Бөек Ватан сугышында катнашкан. Җиңү көнен мәңгелек бәйрәм, дип саныйм. Энергетика өлкәсендә инженер булачакмын, быел диплом елым. Икенче һәм өченче курсларда студентларның төзелеш отрядында эшләдем. Җәйге каникулда эшләп алу кирәк, төзелеш отрядлары ул – хезмәт мәктәбе. Хыялым һәм теләгем – укуны тәмамлап, диплом алу инде. Сагынган чакларда Биектауга кайтып киләм, Казан янында гына бит безнең район.



# Татарлар яшәгән Тугыз авылы су астында

vk.com

**Түбән өлкәсендәге милләттәшләребез яши торган Тугыз авылы инде берничә көн су эчендә утыра. Суның биеклеге 7-8 метрга кадәр күтәрелгән. Авыл халкы мондый су басуны соңгы тапкыр 1999 елда күргән булган. Тугыз авылы кешесе Фатыйма Вабиевага шалтыратып, без анда яшәүче татарларның хәлләрен белештек. Фатыйма апаның сүзләренә караганда, су 11 апрельдән үк керә башлаган.**

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА**

– Көненә 80-90 сантиметрга кадәр күтәрелде. 29 апрельдән бирле суның биеклеге ничек бар, шулай тора. Авылның 156 йорты су астында калды. Аларның 46сы буш тора иде. Су кергән өйләрдә 345 кеше, шул исәптән 118 бала яши. Кайберләре өйләрендәге мебель, кием, табак-савытын алырга яки чормага менгерергә дә өлгермәде. Су бик тиз керде. Тизрәк транспорт, терлекләрне коткарырга тотындылар. Авыл мәктәбендә вакытлыча яшәү пункты ачылды, анда 54 кеше яши. 49ы – балалар, – дип сөйләде ул безгә.

Су китергән зыян шактый булырга охшаган: коймалар, утыннар, түзелеш материаллары агып киткән. Машиналар суда калган. Продукт запасы, мебель, баздагы бәрәңге ашарга яраклы түгел. Авыл читендәге йортларга бигрәк тә зур зыян килгән. Су аларның карнизенә кадәр күтәрелгән. Зыян күрүчеләргә ярдәм яхшы оештырылган.

– Шифаханәдә яшәгән кебек, көненә өч тапкыр тәмле ашаталар, бөтен уңайлыклар да бар. Иллешәр мең сум акча тараттылар. Әмма күңел барыбер тыныч түгел. Бик күп проблемаларның хәл итәсе бар, – ди Фатыйма апа.

Тугыз авылы халкының мал-мөлкәтләре, йортлары, каралты-куралары су астында калу сәбәпле, аларга тиз арада ярдәм кирәк. Кеше кайгысына битараф булмаганнар чиста су, ризык, кием-салым, урын-җир кирәк-яраклары, шулай ук акча белән булыша ала. Акчалата ярдәмне җыю өчен тугызлылар авылларындагы иң хөрмәтле һәм гадел кешеләрнең берсе булган Йусуф әфәнде Зариповны билгеләгәннәр. «Сбербанк» картасының номеры – 639002679010167017, Зарипов Йусуф Айтмухаметович. Теләсә кайсы «Сбербанк» бүлекчәсеннән яисә банкоматтан шушы номерга акча сала аласыз. Йусуфның телефоны +7 982 133 26 20.

Без Йусуф әфәнде Зарипов белән дә сөйләштек.

– Халыктан ярдәм килә башлады. Ике көн элек кенә Казаннан 22 мең сум акча күчерделәр, – диде ул. Рәхмәтләрен дә җиткерергә сорады.

**КАЗАНДАГЫ ГУМАНИТАР ЯРДӘМ ҖЫЮ ПУНКТЛАРЫ:**

*1. «Ярдәм» мәчете (Серов урамы, 4а йорт, телефоны –* ***223-03-59****)*

*2. «Мәрҗани» мәчете (Каюм Насыйри урамы, 17 йорт, телефоны –* ***293-36-86****)*

*3. «Иман нуры» мәчете (Нагорный бистәсе, Дорожная урамы, 32 йорт, телефоны –* ***8 (919) 647-58-06****)*

*4. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, Казан, Карл Маркс ур., 38/5;*

# Учак ягу 1500 сумга төшәргә мөмкин

**5есеннән 20 майга кадәр Татарстанда, Министрлар кабинеты карары белән, аерым янгын куркынычсызлыгы режимы кертелде. Ярамаган җирдә учак якканнарга 1500 сумга кадәр штраф яный.**

Россия хөкүмәте янгынга каршы көрәш кагыйдәләренә үзгәрешләр керткәннән соң, хәзер басу-кырларда да учак ягу тыела. Яңа кагыйдәләр нигезендә, бакчадагы чүп-чарны сыйдырышлыгы 1 куб метрдан артмаган, өсте каплаулы металл бакта яндырырга була яки барлык чүп-чарны бакчада чокыр казып, шунда күмәргә мөмкин. Шашлык пешерүчеләр өчен дә 5 майдан янгын куркынычсызлыгы таләпләре катгыйлана. Шашлык, парламалар мангал, махсус савытларда пешерелсә дә, учак каралты-кура, йортҗирдән кимендә 5 метр ераклыкта булырга тиеш. Янгын сүндерүчеләр учак ягар алдыннан һәрвакыт чиләк белән су алып килеп куярга һәм, ул-бу була калса, хәбәр итәргә телефонның эшлиме икәнен тикшерергә киңәш итә.

Бакчачыларның янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүләрен хәтта космостан спутниклар аша да күзәтергә җыеналар. Шашлык пешерүчеләрне барлыгы 300ләп кисәтү төркеме тикшерәчәк.

## ТОП – 3

**ТАНЫЛГАН** Дю Солей циркы 11 майда кабат Казанга киләчәк. Бу юлы артистлар 4-10 метрлы 300дән артык металл агачтан торган «алтынсу урман» да алып киләчәк. «Татнефть-Арена»да тамаша өчен җиһазларны корырга 12 сәгатьләп вакыт кирәк булачак, ди оештыручылар.

**ГҮЗӘЛ ЯХИНАНЫҢ** «Зөләйха күзләрен ача» әсәренең татарчага тәрҗемәсе «Шәһри Казан» битләрендә басылып барды. 31 май көнне исә Казанда романның татарча вариантын тәкъдим итү кичәсе узачак. Китапны барлыгы 20 телгә тәрҗемә итәргә җыеналар.

**БЫЕЛ** җәй Казанда су юлы буйлап яңа төр маршрут барлыкка киләчәк. «Казанка-Амазонка» маршруты буйлап тизйөрешле катерда Казансудан Зәңгәр күлгә кадәр барырга мөмкин булачак. Бу урыннарда кыргый табигать Амазонка урманнарын хәтерләткәнгә, маршрутны да шулай атаганнар.

## әкәмәт

# Су кызы 10 минут кына яшәп калган

**Һиндстанда 22 яшьлек бер хатын русалка синдромлы бала тапкан. Яңа туган сабыйның аяклары тоташып, су кызыныкыдай балык койрыгын хәтерләткән.**

Гинеколог Вандана Ария сүзләренә караганда, мондый очрак медицинада сирәк очрый. Сабыйның өске өлеше сау-сәламәт булса да, билдән астагы әгъзалары җитлекмәгән була. Шуңа да бала 10 минуттан соң үлә. УЗИ тикшерүе дә бу гадәттән тыш хәлне ачыкларга ярдәм итмәгән. Дөрес, бала туар алдыннан гына аның бөерләре тиешле дәрәҗәдә эшләмәве ачыклана. Бу – дөньяда русалка синдромы белән туган икенче бала. Танылган «су кызы» Шайло Пепин Америкада яшәгән. Табиблар мондый авырулы балаларның җенес органнары булмый, алар иң күбе берничә сәгать кенә яши дисәләр дә, Шайло бишенче сыйныфка кадәр яшьтәшләре белән мәктәптә укыган, 2012 елда үпкәсе ялкынсынып, хастаханәдә бакыйлыкка күчкән.

## АТНА ФОТОСЫ



Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

# Яңа акчадан Казан исе килерме?

**Россия Банкы киләсе елдан 2000 һәм 200 сумлык кәгазь акчалар чыгара башлаячак. Аларның бизәлеше әлегә ачыкланмаган. Россия Үзәк банкы рәисе Эльвира Нәбиуллина сүзләренчә, яңа акчага илнең кайсы шәһәрләрен сурәтләргә кирәклеген халык үзе хәл итәчәк. Димәк, бер елдан Казан Кремле төшерелгән акчага ипи-сөт алу хыялдан чынбарлыкка әйләнергә мөмкин.**

Линар ЗАКИРОВ

Эльвира Нәбиуллина сөйләвенчә, бүген Россия купюраларында ил төбәкләренең йөзек кашлары сурәтләнгән. Бу гадәтне саклап калырга, шул ук вакытта яңа традицияне башлап җибәрергә – сайлау хокукын җәмәгатьчелеккә тапшырырга кирәк.

– Озакламый федераль телеканалларның берсендә бу темага фикер алышуны һәм тавыш бирүне башларга ниятлибез, – дип ачыклык кертте Россия банкы башлыгы.

200 һәм 2000 сумлык купюралар чыгару тәкъдимнәре элегрәк тә яңгырады. 2015 елда инициатив төркем, ике меңлеккә Владивостокны төшерик, дисә, 2014 елда Кырымның шәраб ясаучылары ике йөзлеккә Аю-Даг тавын сурәтләү тәкъдиме белән чыкты. Шул ук елны РФ Дәүләт Думасыннан ЛДПР партиясе депутаты Алексей Диденко, Кырымның Россиягә кушылу уңаеннан, 10 меңлек чыгарырга тәкъдим итте. Депутатны өлешчә ишеттеләр булса кирәк: Үзәк Банк Кырым Республикасы сурәте белән 100 сумлык истәлек банкноты бастырды: бер ягында – Севастополь шәһәре, икенчесендә – Кырымның гаҗәеп табигате һәм мәдәни һәйкәлләре.

1990 елда 200 сумлыклар әйләнештә йөргән иде инде. Баштарак Ленин портреты белән бизәлсә, соңрак аны Кремль сурәте алыштырды. Яңа купюралар акча әйләнеше күләменә тәэсир итмәячәк. Банк табасыннан икеләкләрнең күпме төшәчәге әлегә билгесез.

Соңгы мәртәбә яңа акча – тимер унлыклар 2009 елда, аннан алда – 2006 елда – биш меңлекләр, 2001 елда бер меңлек купюралар әйләнешкә кертелде.

Волгоградның танылган рәссамы Владислав Ковальның яңа акчада үз шәһәрен күрү теләге шулкадәр көчле, 200 сумлык банкнотның дизайнын инде әзерләп тә куйган. Тик анда 200 түгел, 250 саны тора.

– Заманында Мәскәүдә 250 сумлык банкнотның проектын элеккеге губернатор Анатолий Бровко тәкъдим иткән иде. Югарыда җитди кабул итмәделәр. Тик мин барыбер Россиядә 250 сумлык банкнот кирәк, дигән фикерне алга сөрәм. Кибетләрдә акча ваклауның нинди мәшәкать икәнлеген чамаласак, 250лек сатып алучыларга да, сатучыларга да кулай булыр иде. Әгәр Үзәк банк 200лек чыгарырга уйлаган икән, элеккеге эскизымны төзәтү кыенлык тудырмас, – дигән рәссам.

**Кайсы шәһәр кайсы акчага хуҗа (банкнотлар)**



**10 сумлык –** Красноярск



**50 сумлык –** Санкт-Петербург



**100 сумлык –** Мәскәү



**500 сумлык –** Архангельск



**1000 сумлык –** Ярославль



**5000 сумлык –** Хабаровск

Сүз уңаеннан, ул тәкъдим иткән акчаның бер ягында Ватан-Ана һәйкәле сурәтләнгән.

Танылган рәссам фикеренчә, ике меңлек кәгазь акчада республикаларның берәмлеге чагылырга тиеш. Ул анда Владикавказ, Элиста яки мәчетләре белән бергә Казанны күрергә тели.

Ниһаять, башкалабыз Казанга да килеп җиттек. Интернетта change.org дип аталган петицияләр сайты бар. Халык, мәсьәләне чишү өчен, петиция ачып, аны хуплау йөзеннән, электрон рәвештә үз имзасын калдыра. Альберт Хәснуллин 200 сумлыкта Казанны сурәтләү турында мөрәҗәгать булдырган.

– Казан 200 сумлыкта үз урынын алырга хокуклы. Минемчә, ул мәдәният, икътисад һәм спорт өлкәләрендә үсеш буенча ил төбәкләренең беренче өчлегендә бара. Казан илебезнең күпйөзле икәнлеген дә чагылдыра! Мәчетләр һәм православие Храмнары инде ничә гасырлар янәшә тора. Бу бөтен төбәкләр өчен дә үрнәк, – дип язган Альберт. Петицияне ике меңләп кеше хуплаган.

Change.org сайты оештыручылары хәбәр итүенчә, ике көндә яңа акчадагы бизәлешкә кагылышлы 1300 петиция ачылып, 80 мең кеше тавыш биргән. Халык ни генә күрергә теләми: Байкал күле белән Эльбрус тавыннан башлап Путин, Толстой, Ломоносов, Гагарин, Сталин, Тула перәннеге, хәтта Чак Норрис сурәтенә кадәр.

Берәү, яңа купюрага Панама дәүләтен төшерик, дип: «Әлеге төбәк Россияне мәдәни яктан баетуга зур өлеш кертте», – дип аңлатма биргән.

Хәзерге вакытта иң популяр петиция ике меңлектә Владивостокны сурәтләүгә бәйле. Аннары тавыш саны буенча Кострома, Волгоград, Краснодар, Якутск, Пермь, Байкал күле, ике мең еллык юбилеен бәйрәм итүче Дербент (Дагыстанда), Новосибирск һәм Севастополь бара.

Берничә ел элек петиция ярдәмендә 36 мең британлы үз банкнотларында хатын-кыз сурәтенең барлыкка килүенә ирешә. Быел шундый ук чара Канадада җиңеп чыга. Яңа акчалар әлеге илләрнең үсешенә хатын-кызның нинди зур өлеш керткәненә ишарәли.

Австралиядән Конор исемле 12 яшьлек сукыр малай тырышлыгы белән узган ел 5 долларлык купюраларда махсус билгеләр барлыкка килә. Алар ярдәмендә, күрмәүчеләр акча белән җиңел генә куллана.

Россиянең бүгенге кәгазь акчаларына игътибар итсәк, анда Идел буе федераль округының бер шәһәре дә юк. Әгәр тавыш бирүдә Владивосток җиңеп чыкса, купюраларда Ерак Көнчыгыш федераль округыннан ике шәһәр була, дигән сүз (биш меңлектә шул җирлектән Хабаровск сурәтләнгән).

«Википедия» мәгълүматларына күз салсак, 2014 елның тулаем төбәк продукты (ВРП) күрсәткечләре буенча, Үзәк федераль округтан соң, Идел буе округы – икенче урында, ә Ерак Көнчыгыш округы – җиденчедә. Кеше саны буенча да без Үзәк федераль округтан гына калышабыз. Шулай булгач, Казанны ук булмаса да, Идел буендагы берәр башка шәһәрне яңа акчага «индерергә» кирәк бит инде. Ә шулай да Казанның – Россиянең өченче башкаласы икәнлеген дә онытасы түгел, җәмәгать. Җитмәсә, чал тарихлы калабыз Идел буендагы иң борынгы шәһәр дә бит әле. Билгеле булганча, олыларга урын бирергә кирәк. Һәрхәлдә, тәрбияле кешеләр шулай эшли...

**Чаллыдан Мисбах бабай, коммуналь хезмәтләр өчен түләп барсам да, бурычларым җыела, дип шалтыраткан иде. Баксаң, укучыбыз торак-коммуналь хезмәтләр өчен счет-фактурада күрсәтелгән сумманы түгел, ә үзе теләгәнчә түли булып чыкты. Шуңа да аның бурычлылар исемлегенә эләгүе гаҗәп түгел. Мондый «ничек телим, шулай түлим», дип яшәгән кешеләр бер Мисбах бабай гына түгел шул. Татарстанның торак-коммуналь хуҗалык тармагында Иҗтимагый контроль үзәге директоры Дмитрий Романов әйтүенчә, республика буенча торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурыч 5 миллиард сумнан артып киткән.**

# «Лампочка янмаса да, Президентка язалар»

Әлеге Иҗтимагый контроль үзәге республикада 2014 елдан бирле эшли. Гозерләрне җиткерү өчен махсус «кайнар элемтә» номеры бар, шулай ук атнага биш тапкыр халыкны кабул итәләр. Ел саен үзәктә теләгән кешеләргә торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә белем бирәләр. Былтыр гына да шул рәвешле 800 кеше укып чыккан. Идарә итү компаниясенең вазифалары, милек хуҗасына куелган таләпләр, торак-коммуналь хезмәтләр нәрсә ул – барысын да җентекләп аңлаталар. Укуларның файдасы да юк түгел, кеше барысына да төшенгәч, вакытында түләп бара башлый ди.

**– Бурычлыларның исемлеге һәрчак йорт подъездларында эленеп тора. Хәтта 200 мең сумга кадәр бурычлары җыелган кешеләр бар. Кеше акча юклыктан түләмиме?**

– Алай димәс идем. Бурычлы кешеләрнең бик азы гына авыр шартларда яши. Күбесенең эш урыны, акчасы бар. Еш кына идарә итү компаниясе белән аңлашылмаучанлыклар, счет-фактурадагы мәгълүматны аңламаулары аркасында, ОДН түләргә теләмичә, исәпләнгән суммадан канәгать булмыйча, түләүдән баш тарталар. Яки акчасы булып та, үз белдекләре белән теге яки бу хезмәт өчен түләргә тиеш түгелмен дип, түлы сумманы күчермиләр. Бу Торак кодексын белмәүгә бәйле. Идарәче компанияләр белән фатир хуҗалары арасында килешүләр булмау да эшне катлауландыра.

**– Нинди килешүләр турында әйтүегез, алар закон нигезендә төзелергә тиешме?**

– Әйе. Торак кодексында әйтелгән закон буенча, идарәче компанияләрнең вазифалары, фатир хуҗаларына куела торган таләпләр төгәл күрсәтелгән килешүләр булырга тиеш. Бу документның һәр идарәче компаниягә сайтларында урнаштыру таләбе дә куелды.

**– Кешеләргә коммуналь хезмәтләргә түләүләрне аз булса да киметү өчен нинди киңәшләр бирә аласыз?**

– Беренче чиратта, исәпләү җайланмалары куйдырсыннар. Бу чыгымнарны шактыйга киметә. Һәр төбәк коммуналь хезмәтләргә тарифларны үзе билгели. Шуңа да бездә болай, сездә тегеләй, дип чагыштырырга кирәкми. Аңлашылмаучанлыклар килеп чыкканда, идарә итү компанияләренә, безгә мөрәҗәгать итәргә була. Алайса кешеләрнең күбесе, лампочка янмаса да, тизрәк Президентка хат язарга тотына. Югыйсә проблеманы башкача да хәл итеп була.

**– Түләмәгән өчен нинди җәза каралган?**

– Фатирдан куып чыгармыйлар. Аның каравы, теге яки бу хезмәттән файдалануны туктатырга мөмкиннәр. Әйтик, бәдрәфкә килә торган торбага подъезд аша махсус җайланма куеп, суны туктату алымын еш кулланалар.

**Редакциядән.** Әлеге теманы газетабызның киләсе саннарында да дәвам итәрбез. Торак-коммуналь түләүләргә кагылышлы сорауларыгыз булса, **562-50-03** телефоны аша редакциягә юллый аласыз. «Шәһри Казан» сезне тыңлый.

Эльвира МОЗАФФАР.

**Торак-коммуналь хезмәтләргә бурычы булганнарның чит илгә чыкканда проблемалары килеп туарга мөмкин. Быелның 1 гыйнварыннан кергән закон нигезендә, коммуналь хезмәтләр өчен 90 көн эчендә түләмәгән кешеләрнең бурычына өстәлә торган пени 17 процентны тәшкил итә. Моңа кадәр ул 8 процент иде.**

# «Үлемсез полк» – хәтер сагында

**«Үлемсез полк» акциясе – 9 Май бәйрәменең тагын бер күркәм традицияләренең берсе. Халык сугышта катнашкан, яу кырында ятып калган туганнарының истәлекле фотосурәтләре белән урамга чыга.**



Илсөя Гәрәеваның шәхси архивыннан алынды

Алисә САБИРОВА

– Узган ел оештыру эшләре белән мәшгуль булу сәбәпле, акциядә үзем катнаша алмадым. Быел катнашырга исәп. Бабамның әтисе сугышта хәбәрсез югалган. Кызганыч, бүгенге көндә аның турында безнең гаиләдә мәгълүмат бик аз. Фотосы да Мари Эл республикасында яшәүче туганнарда. Чарага кадәр аның фотосурәтен барып алырга исәп. «Үлемсез полк» гаилә тарихын белергә, сакларга ярдәм итә. Биредә туганнары турында нинди дә булса мәгълүмат ишетүчеләр дә булды, – ди акциянең Казандагы координаторы Кирилл Шабалин.

Илсия Гәрәева исә ветеран әби-бабасының истәлекләрен кадерләп саклый. Узган ел ул аларның фотоларын зур плакатка ябыштырып чыккан. Бабасы Галимгаян Фәррахов сугышка 1941 елның 22 июнендә үк киткән. Ике тапкыр яраланган. Бер барелештә дошманның штабына ук үтеп кереп, андагы офицерларны әсирлеккә төшерәләр, мөһим документлар да кулга керә. Бу батырлыгы өчен Галимгаян Фәрраховны Беренче дәрәҗә Кызыл Йолдыз ордены белән бүләклиләр. Шулай ук Ленинград, Сталинград, Елгава шәһәрләрен дошманнан азат итүдә катнаша ул. Әбисе Рәйсә Фатыхова өчен сугыш педагогия көллиятенең чыгарылыш кичәсен тәмамлаган көннән башлана. Шул вакытта 19 яшьлек кыз, ике дә уйлап тормый, үзе теләп, фронтка китә, зенитчы була. Берьюлы аларның полкы ике көн эчендә 83 танк, 15 автомашина, ягулык тутырылган 2 цистерна һәм 14 самолет шартлата.

–Минем әби белән бабайны тормыш сугыштан соң таныштыра. Бер мәктәптә эшлиләр. 1946 елның 9 маенда өйләнешәләр. 59 ел тигез, матур тормыш итәләр. Кызганычка, алар безнең янда юк инде. Дәү әтием белән дәү әнием безнең гаиләнең генә түгел, һәммәбезнең горурлыгы! – ди Илсия.

Илсия бәхетле кыз, чөнки сугыш турындагы хатирәләрне аңа әбисе белән бабасы үзләре сөйләп калырга өлгергән. Ә хәзер ул алар турында башкаларга да горурланып сөйли.

– «Үлемсез полк»та катнашканда бөтенләй дә таныш булмаган кешеләр дәү әти белән дәү әниең тарихы белән кызыксындылар. Әби-бабай фотолары белән әлеге акциядә безнең Уфа шәһәрендәге туганнар да катнашты. Анда дәү әнинең бертуган абыйсы яши. Ул да бөтен гаиләсенә апасының батырлыгы турында гел сөйләп тора. «Үлемсез полк» акциясе геройлар турында истәлекләрне саклап калырга ярдәм итә», – ди Илсия.

## Ничек катнашырга?

– Быел «Үлемсез полк» акциясендә Казаннан 20 меңләп, гомумән, республикада 62 мең кеше кушылачак, – дип хәбәр итте Татарстан Президенты ярдәмчесе Ләйлә Фазлыева. Рөстәм Миңнеханов үзе дә катнашачак.

Әлеге чарада теләгән һәр кеше катнаша ала, сүз уңаеннан, «Үлемсез полк»ка сугыш ветераннарын гына түгел, тыл хезмәтчәннәрен дә тәкъдим итәргә була. Акция 9 май көнне узачак. Колонналарга тезелү 14.00 сәгатьтә «Казан» милли мәдәният үзәге янында башланачак. «Чарага артык әйберләр алып килмәсәгез яхшырак, хокук сакчылары һәр кешене дә җентекләп тикшерәчәк», – дип кисәтте республика премьер-министр урынбасары Васил Шәйхразиев. Чара үзе 15.00 сәгатьтә башланачак. «Үлемсез полк»та катнашучылар быел Пушкин урамы буйлап Черек күлгә юнәләчәк, аннан Чернышевский урамы аша Кремльгә юл тотачак. Соңгы нокта – 1 Май мәйданы.

«Үлемсез полк»та иң төп атрибут – ул транспарант. Аны тышкы реклама бирү белән шөгыльләнгән фирмаларда 500 сумга заказ биреп ясатырга, үзеңә кулдан эшләргә дә була. Рамкага фотодан тыш якыныгызның исем-фамилиясен, әтисенең исемен дә язарга онытмагыз. Шулай ук яшәгән елларын, хезмәт иткән полкы турында мәгълүмат урнаштырырга да була.

# «Сугышны урамда малайлар сугышкан кебек күз алдына китерә идек»

**Ришат Төхвәтуллинга сәхнәгә ак чәчәкләр менгергән ак яулыклы сөйкемле әбигә тамашачы рәхәтләнеп кул чапты. Туксан яшенә дә күп калмаган Мөнәвәрә әби Галиева татар спектакльләренә дә, концертларына да яратып йөри. Әмма Ришатның чып-чын фанаты ул. Бигрәкләр дә яратам инде үзен, ди. Ришатның концертын дүртенче тапкыр карый икән. Тыйнак, мөлаем татар әбисе белән якыннанрак танышырга дип, аның оныгы өенә юл тоттык. Сүзебезне тиздән җитәчәк Җиңү көненнән башладык. Бәйрәмне ул Мәскәүдә – кызы янында каршыларга җыена.**

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Мәскәүгә барып кайтам да, җәйгә торырга туган ягыма – Лениногорск районы, Бухар авылына китәм. Җәен – авылда, кышын оныгым янында Казанда яшим. Туган-үскән җир бик якын бит ул. Шунда тудым, шунда гомер иттем. Колхозда, яшелчәчелектә эшләдем. Сугыш башлану хәбәрен дә яшелчәчелектә эшләгәндә ишеттек. Сугышны без баштарак урамда малайлар сугышкан кебек кенә күз алдына китерә идек. Һәр көнне авылдан ирләр сугышка чыгып китә башлагач кына, аның хәтәр нәрсә икәнен аңлый башладык. Бертуган абыем да китте, апамны ФЗӨгә җибәрделәр. Ничек кенә авыр булса да, сыерны бетермәдек, бәрәңгесен утырттык. Шуның белән генә ачтан үлмәдек. Ирләр калмагач, бөтен эш хатын-кызлар, үсмер балалар кулына калды. Үгез җигеп сабанын да сөрдек, тырмасын да тырмаладык, урагын да урдык, печәнен дә чаптык. Әле ул үгезне тыңлату мең бәла. Ятса, торгызып булмый. Атлар юк, булганы да бик арык, салам гына ашап торгач, ничек хәлләнеп китсеннәр. Яз көне ике кешегә бер арба тартып, Әлмәт районыннан чәчүлеккә дип бәрәр центнер симәнә тартып кайта идек. Урман кисәргә дә йөртәләр. Анда баручыларга берничә килограмм он бирәләр иде. Иң яманы да шул ачлык булды. Эшне эшлисең инде аны, ашарга сораган ашказанын гына тынычландырып булмый. Барасы килми дә бит, котыла алмыйсың, сугыш вакыты, ничек баш тартасың дип өркетеп торалар. Төрмәгә утыртып куюдан бик курыктык, кырдан бернәрсә дә урлап кайтмадык. Халык түздә, сабыр итте. Җиңү өчен бөтен нәрсәне дә эшләде. Абыем сугыш бетеп бер ел да бер ай узгач кына кайтты. Контузия булып, Венгрия хастаханәсендә яткан. Сугышка өйләнеп киткән иде, ул кайтышка хатыны мәрхүм булды. Баласын без карап үстердек. Абый кайтканда, аңа биш яшь тулып киткән иде инде, – дип сөйләде ул безгә.

Мөнәвәрә әби кияүгә, үзе әйтмешли, бик соң чыккан. Аңа ул вакытта егерме яшь булган икән инде (!). Ире Мәүлетҗан белән илле елга якын бергә яшәп, бер ул, бер кыз үстергәннәр.

– Ирем бик әйбәт кеше булды, аның белән дус-тату яшәдек. Кызым да, оныгым Илмира да ирләреннән бик уңдылар. Аллага шөкер, алар өчен куанып бетә алмыйм, – ди әби.

Сәхнәдә бик чая күренгән Мөнәвәрә әби артык тыйнак булып чыкты. Фотога медальләрен тагып төшәргә һич тыңлата алмадык. Бәйрәмнәрдә медаль тагып килергә кушканда да, кулым белән каплап барам, ди ул. Әллә нинди зур батырлык күрсәткән кеше түгел лә мин, дип тә куя. Сугыш чорының бөтен авырлыгын күтәргән, ачлыкны-ялангачлыкны күргән үтә дә тыйнак Мөнәвәрә әби бүгенге тормышны оҗмах белән тиңли.

– Җәннәт әллә кайларда түгел, ә җир өстендә. Ашарга да, кияргә дә бар. Без элек бушка эшләдек. Бер тиен дә акча күрмәдек. Ә хәзер хезмәт хакын да, пенсиясен дә түлиләр. Алланың биргәненә шөкер. Тыл ветераннарын да онытмыйлар, бүләкләрен дә бирәләр, хөрмәт тә күрсәтәләр, – ди ул. Ә медальләрен барыбер такмады, кулыңа гына булса да тотып төш инде алайса дип, көчкә күндердек.

**Бу көннәрдә машина йөртүче танышларым арасында ыгы-зыгы купты. Кайсы белән генә сөйләшмә, штраф түләттерүләрдән зарланалар. Машиналарын тротуар яки газонда калдырган өчен берсенә – ике мең, икенчесенә хәтта җиде мең ярым сум штраф килгән. Болар бер атна эчендә! Ул арада интернетта да штрафларны протокол төземичә генә яза башладылар дигән (соңыннан аңлашылганча, ул дөреслеккә туры килмәде) хәбәр таралды.**



# Парковкалар проблемасын штрафлар салып кына хәл итеп булмый

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА**

### ЕЛЫНА ҖИДЕ МЕҢЛӘП ШИКАЯТЬ КАБУЛ ИТЕЛӘ

Машина йөртүчеләргә парковка кагыйдәләрен бозган өчен җәза бирүне гадиләштерү идеясе белән Казан шәһәр Думасы депутатлары чыккан икән. Әлеге мәсьәлә белән алар республиканың Дәүләт Советына мөрәҗәгать иткән. Танышларым исә, парламент әле аны расламаган, ә штрафлар килә башлады, дип сукрана. Әлеге мәсьәләгә ачыклык кертүне сорап, без Казан башкарма комитеты административ-техник инспекция идарәсенең җәмәгатьчелек белән элемтәләр белгече Рафаэль Шәрифуллинга шалтыраттык.

– Әлеге штрафлар яңа система буенча җибәрелмәгән, бу берничек тә мөмкин түгел. Ни өчен дигәндә, Дәүләт Советы әлегә бу тәкъдимне карамады. Ул кайчан каралыр – анысы билгесез. Машинаны газонда, балалар мәйданчыгында, парк-скверлар, ишегалларының яшел зоналарында калдырган өчен штрафларны элек тә язалар иде. Һәр дөрес куелмаган машина өчен инспектор протокол төзи иде. Башта машина йөртүченең кем икәнен ачыкларга, аннары протокол төзү турында аңа хәбәр итәргә, ул алындымы икән дип почта хезмәтеннән җавап көтәргә туры килде. Хәзер исә аларны протокол төземичә генә язалар. Кагыйдә бозу «Паркон» ярдәмендә автомат рәвештә теркәләчәк. Фотога төшерәләр дә, ул административ комиссиягә китә. Комиссия исә штраф салу турында карар чыгара. Яңа система автомобильнең газондамы, юлдамы калдырылганы турындагы бәхәсләрне дә чишәргә ярдәм итәчәк. Кайбер ишегалларында алар буталып беткән. Бордюрлар юк, газоннарда чирәм үсми. «Паркон»нар исә, GPS буенча, яшел зоналарның чикләрен билгеләячәк, – дип сөйләде безгә Рафаэль Шәрифуллин.

Ә танышларыма килгән штрафларны ул ЮХИДИ идарәсе яки административ-техник инспекция идарәсе аша килгән штрафлар белән аңлата.

– Административ-техник инспекция инспекторларын аларны протокол төзергә чакырган булырга тиеш. Монысы элеккеге система буенча эшләнә. «Халык контроле» дә бик актив эшли. Шәһәр халкын машиналарны газонда калдыру кебек мәсьәләләр бик борчый. Елына шундый җиде меңләп шикаять кабул ителә. Яшел зонага менеп кунаклаган машиналарны фотога төшерәләр дә «Халык контроле»нә җибәрәләр. Алар исә ЮХИДИга «озата». Штрафны алар салган булып чыга. Ә танышларыгызга штрафларның шулай күпләп һәм көтмәгәндә килүе ул очраклылык кына, – диде әңгәмәдәшем.

### КҮБРӘК АКЧА ЭШЛӘҮ БЕЛӘН МАВЫГАЛАР

Россия машина йөртүчеләр федерациясе төбәк вәкиле Рамил Хәйруллин исә, парковкалар проблемасын штрафлар салып кына хәл итеп булмый, дигән фикердә тора.

– Шәһәр җирендә парковкалар бик кирәк. Әмма аларны бөтен җирдә дә ясап булмый. Казанның иске өлешендә, әйтик, бу берничек тә мөмкин түгел. Дөресе, мөмкин, әмма парковка хакына кемнәргәдер уңайсызлык тудырырга туры килә. Яшел зонаны йә булмаса балалар мәйданчыгын киметү бөтен кешегә дә ошап бетмәячәк. Парковка ясауны таләп итеп була, тик аны үтәп кенә булмый шул. Кирәксез урында машина калдыручылар белән көрәшү өчен бордюрларны биегрәк итеп эшләргә, коймалар куярга була. Нәтиҗәдә, ул газонга берничек тә керә алмаячак. Миңа күбрәк акча эшләү белән мавыгалар кебек тоела. Газон өстендә торган машинаны көн дә фотога төшерергә була. Штрафлар шактый җыела, акча да күп керә. Башта без үзебезгә нәрсә кирәклекне хәл итик: яшел зонаны сакларгамы, әллә штраф җыярга телибезме? – ди ул.

Рамил Хәйруллин проблеманы чишәр өчен «Халык гаражлары» дигән дәүләт программасын эшләргә кирәк дип саный:

– Берничә ел элек эшләп тә карадылар кебек аны. Кайдадыр ул мөмкин дә булгандыр. Казанда ул эшләп китмәде. Ишегалларында муниципалитетлар бер катлы гадәти кирпеч гаражлар төзи дә аны арендага бирә яки ваклап түләү шарты белән сата. Ул гаражларның бәясе социаль булырга тиеш. Иске ишегалларында да гаражлар өчен мәйданчык табарга була, минемчә.

– Ни өчен парковка түгел, ә гараж?

– Бу психологик момент. Кешенең нинди дә булса дурт почмагы бар икән, ул аны үзенеке итеп кабул итә, аңа сак карый. Әйләнә-тирәсен җыештыра, себерә, тәртиптә тота. Анда ул нәрсә дә булса саклый да ала. Шаяртып әйткәндә, кемнән булса да качып та утыра ала. Ә парковка бит ул – бөтен кешенеке дә, гап-гади асфальт кисәге. Штраф штраф белән, ә кешеләрдә сайлау мөмкинлеге булырга тиеш. Машинасын кая куярга тели – шунда куйсын, парковкага да, гаражга да куя ала. Теләсә, газон өстенә дә менсен...



Казан мэры **Илсур МЕТШИН** «Тема» тапшыруында:

– Бездә бит халык бер аягы белән парковкада, икенчесе белән подъездда булырга ияләнгән. Дөнья үзгәрде. Паркинг мәсьәләләрен хәл итәр өчен бизнесны җәлеп итәргә, күп яруслы парковкалар төзергә кирәк. Тиздән машина хуҗалары тимер атларын йортларыннан 10-15 минут барырлык ераклыкта калдырачак. Үзеңнең дә, балаларыңның сәламәтлеге өчен дә файдалы. Алар ишегалдындагы газны иснәмәячәк, анда исә яшеллек, матурлык булачак. Быел Казан ишегалларында өстәмә өч мең урынлык парковкалар төзеләчәк.

# ТОРМЫШМЫ БУ?

## «Картаймыш көнемдә үзем салган йортка үзем хуҗа була алмыйм», – ди сугыш ветераны Габдеразак бабай

**«Әти – сугыш ветераны. Апабыз аның йортын яшерен рәвештә энекәшебезгә сатканнан соң, әти ачлык игълан итте, инде җиде көн берни ашамый, 9 килога ябыкты. Ярдәм итегез», – дип шалтыратты безгә укучыбыз Камил Каюмов. Әлеге вакыйгага ачыклык кертү өчен, Каюмовлар яшәгән Яңа Сосновка бистәсенә юл тоттык.**



Эльвира МОЗАФФАР

### «КЫЗЫМ ЯЛГАНЛЫЙ ДИП УЙЛАМАДЫМ ДА»

Габдеразак абыйны бистәдә белмәгән кеше юк. Мәчеттә мулла булып та торган ул, хөрмәткә лаек, акыллы, пөхтә, ягымлы бабай. Хәзер дә биш вакыт намазын, уразасын калдырмый, Коръән ашарына да еш чакыралар үзен. Хатыны Гадилә апа белән биш бала тәрбияләп үстергәннәр.

– Арабызда бердәнбер кыз – Галия апа иркә булып үсте, – ди Камил абый. – Әтинең яраткан кызы иде шул, без малайлар булсак та, идән дә юдык, ашарга да пешердек, ә аңа, кыз кеше дип, иң матур киемнәрне алдылар, өрмәгән җиргә дә утыртмадылар. Дөрес, апа бик яхшы укыды, аны әти-әни безгә гел үрнәк итеп куялар иде.

– Галия генә ышанычымны акламады шул, – дип уфтана шунда Габдеразак бабай.

Әниләре бакыйлыкка күчкәннән соң, аның белән бергә гаиләдәге татулык, тынычлык та югала.

– Хатыным белән 56 ел бергә яшәдек, шундый рәхәт, күңелле чаклар иде ул. Башта Һади Такташ урамында тордык, аннары ул җирләрне төпчек улыбыз Мансурга калдырып, Яңа Сосновка бистәсенә күчендек, монда йорт сала башладык. Умарталарыбыз да бар иде. Хатынымны бер көн исемә төшерми калганым юк, ансыз бик авыр, – ди Габдеразак бабай.

Ул бу югалтуны авыр кичерә, озак кына хастаханәдә дәваланып чыга. Бер күзе бөтенләй күрмәс була, икенчесенә операция ясата. Ул чакта аны һәрчак кызы Галия җитәкләп йөри, янынннан китми. Шул арада әниләре исемендәге йортны әтисенә күчерергә дә булыша. Моның белән генә туктап калмыйча, әтисеннән үзенә торак белән идарә итү мөмкинлеге биргән ышанычнамәгә дә кул куйдырта.

– Кызым мине ялганлый алыдыр дип уйламадым да, ә ул миңа әйтми генә торагымны алган да, хәзер менә йорт төпчек улым Мансур исемендә. Суд барышында апасыннан 900 меңгә сатып алганы ачыкланды. Әле ул акчаларны миңа бирдем диде, тик бер тиенен дә күргәнем юк, моны бит аферистлар гына булдыра ала, моның өчен җәза да каралган. Бу вакыйгалар белән үзем юрист булып беттем инде. Законнар укыйм, – ди Габдеразак бабай.

### «ӘТИНЕ УРАМГА КУУЧЫ ЮК»

Галия апа да, Мансур абый да әтиләрен урамга куып чыгарырга җыенмыйлар анысы.

– Мин туганлык яклы, элек әтине шифаханәләргә дә йөртә идем, хәзер дә зарланырлык түгел инде хәле, ашарга пешкән, мунча ягылган. Дөрес, әти бездән аерым ашый башлады. Чөнки олы улы Камил котырта. Әти гел, йорт Галиягә калыр инде, дип, сөйли иде. Шуңа да апа аны үз исеменә күчерткәндер инде, аннары миңа сатарга булды. Йорт кем исемендә булудан нәрсә үзгәрә? Әтине беркем йорттан кумый, исән-сау яшәсен, – диде бакчасында эш белән мәшгуль Мансур абый.

Тик Габдеразак бабайның мондый шартларда яшисе килми бугай.

– Тормышмы бу: картаймыш көнемдә үзең салган йортка үзең хуҗа була алма инде! Торакны



Автор фотосы

> Татарстандагы кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиллек белгече **Әлфия ГАБДРАХМАНОВА:**
>
> – Күп нәрсә ышанычнамәнең эчтәлегенә бәйле. Әгәр ышанычнамә килешүендә фатирны сату, арендага бирү яки башка шундый гамәлләр башкару турында әйтелгән икән, йорт хуҗасы исән булган очракта да, ышанычлы зат сатып-алу эшләрен башкарырга хаклы. Әмма йортта теркәлгән кешене берәү дә суд карарыннан башка куып чыгара алмый.

җиткергәндә берәү дә булышмады бит. Мансурга беренче йортыбызны калдырдык, ул аны өч бүлмәле фатирга алыштырды, кызымның да коттеджы бар, һәр балам җитештә яши, ә әтиләре мәче баласыдай кирәксезгә әйләнде, гаделлек кайда монда? – ди ул.

Сүзгә улы Камил дә кушыла:

– Апа гына гаепле, ниндидер һинд сектасы белән бәйләнде дә хаталар кыла башлады, барыбызны да үз өлешебездән баш тартырга мәҗбүр итте.

Әти балаларын каргамый, әмма йөрәк рәнҗеше җиргә төшми бит. Камил абый әйтүенчә, Мансур абыйның әтисен кыйнаган чаклары да булган. Моның өчен Габдеразак бабай улын судка да биргән. Әмма суд карар чыгарыр алдыннан гына, баласын кызганып: «Мин Әфган сугышында катнашкан улымны кичерәм», – дигән. Бу хакта сораша башлагач, Мансур абый белмәмешкә салышты.

Бу хәлләр турында Каюмовларның тагын бер уллары – Мөхтәр абый белән дә сөйләштек.

– Гаебебез булса, әти кичерсен. Миңа үземнеке үземә җитә, әтидән бер нәрсә дә кирәк түгел. Картлык көнендә аңа да суд юлында йөрмәскә иде дә бит. Татулашырга вакыт инде, бик күңелсез мондый хәлләрнең килеп чыгуы, – диде ул.

Галия апаларының ни өчен шулай әтисенә әйтми генә яшерен сату-алу эшләрен алып барганын берәү дә аңлата алмый. Күпме генә тырышсак та, Галия апа белән элемтәгә керә алмадык. Туганнары, трубканы алса да, сөйләшмәс, ул хәзер нык үзгәрде, чүплектән кинә, аның янында басып тору да оят, диделәр. Галия апаның улы Наил абый – «Казан нуры» мәчетендә хәзрәт. Дәү әтисе белән аралашмаганга да бер ел була икән инде.

– Әни үз акылында, шөкер, безнең белән яши, үзе белгән урыннарга бара инде ул, сектага эләгүе турында берни әйтә алмыйм. Камил абый журналистлар чакыра ул, тик менә үзенең гаепләрен дә онытып бетермәсен иде. Аннары, диндәге кеше үз улын судка биреп, дөрес эшләдем дип уйлыймы икән? – дип кенә өстәде.

Адвокат Равил Габдеразаков, тәҗрибәле белгечләр ярдәме белән әлеге эшне судта отарга да була, ышанычнамә көчләп яздырылган булуы да бар, судка мөрәҗәгать итсеннәр, дип киңәшен бирде.

Суд юлын озак таптаган инде Каюмовлар. Бәлки, ниһаять, барысына да күз йомып, бер-берсен гафу итеп, гаиләләрендәге татулыкны, җылылыкны кайтарырга вакыт җиткәндер. Бабаларының 15 оныкы, оныкчыгын да юньләп күргәне юк ләбаса. Ә ул аларга күпме «тере» тарих, сугыш еллары истәлекләрен тасвирлый алыр иде. Мәскәү астындагы үзәккә үтәрлек салкыннарны, немец солдатларының суыктан чебен кебек кырылуларын әле дә сөйли ул. Сентябрьдә Габдеразак бабайга 87 яшь тулачак. Бәхет өчен аңа бер җылы сүз, якты караш җитә. Сугыш елларындагы истәлекләрен сөйләшеп утырганда Габдеразак бабай безнең белән чәйләп тә алды, шөкер. Аннары, бәйрәмгә күчтәнәчләр алып куйыйм әле, дип, кибеткә китте...

# «Иң яхшы эш коралы – сынган пычак»

**Кыз баланы бирнә сандыгы белән кияүгә бирү бер бүген генә уйлап чыгарылган нәрсә түгел. Альберт Гарипов та әнә кызы Алсуны кияүгә биргәндә, йоласына туры китерим дип, бөтен эшен читкә куеп, сандыкка утыра. Альберт тотынгач, аныкы кешенеке сыман гына буламы соң инде?! Сырлап, чокып ясый торгач, шактый затлы чыга эше. Сыртлап бирнә төярлек итмәсә дә, бөтен күңел байлыгын, йөрәк җылысын салуы хак әти кешенең әлеге кечкенә сандыкка.**

**ОСТА**


Автор фотосы

**Расиха ФӘИЗОВА**

Хәер, нәрсәгә тотынса, шуны коеп куя торган кеше Альберт. Өенә керүгә үк монда талымлы оста яшәвен чамалыйсың. Ни хикмәт, кечкенәдән балта эшенә кулы ята аның. Үчалле мәктәбендә 5-6нчы класста укыганда, рәсем-сызым укыткан Фәтыйх абыйлары Солтанов оештырган «Оста куллар» түгәрәгенә йөргәндә үк урындык ясаган малайдан ни көтәсең инде тагын?! Шул вакытта ук әтисе Мөсәгыйть ага да: «Синең кулыңнан килә», – дип, улын үсендерә торгач, малай мунчага ишек, тәрәзәне үзе ясап куя. Алга таба һөнәр сайлавына да шушы балачак мавыгулары сәбәп була. Мәктәпне тәмамлап, читтән торып Уфа физкультура техникумына укырга керүгә, үзе дә Фәтих абыйлары кебек, сызым рәсем, хезмәт, физкультура укытучысы булып китә. Балта тотардай малайларны җыеп, түгәрәк оештырып җибәрә. Башта Ютазы районының Кара Зирек авылында, аннан соң туган ягы – Азнакай районы, Әсәй авылына кайтып, анда дүрт елдан артык укыта. Хезмәтеннән аерылмый гына Алабугада педагогия институтын тәмамлый. «Марат» колхозында парторг вазифаларын башкарганда да, билгеле инде, Альберт ихатадагы балта эшен кешегә кушмый. Укыту-производство комбинатында директор булып эшләгәндә дә, коррекция мәктәбендә укытканда да егетләрнең куллары балта эшенә ятып торсын өчен аз тырышмый Альберт Гарипов.

Кулы белән төймә генә төйми, дип нәкъ менә аның кебекләр турында әйтәләр дә инде. Иманым камил, кирәксә, анысын да тел-теш тидермәслек итеп төеп бирәчәк ул. Чөнки даны юкка гына алтын куллы оста буларак чыкмаган бит инде аның. Гадәттә, район үзешчәннәренең смотр-концертлары вакытында район һәм шәһәр мәдәният йортында кулланма-гамәли сәнгать осталарының эшләре белән дә танышырга була Азнакайда. Менә шунда күрәсең инде кемнең нәрсәгә сәләте иканен. Альберт Гариповны да, нигездә, шушы күргәзмәләр таныта халыкка. Агач эшләнмәләр остасы буларак, беренче урыннарны да әлеге күргәзмәләрдә ала ул. Хәзер инде эшләре күргәзмәләрдән кайтып керми дисәк тә, арттыру булмас. Өендәге көзге рамнары да, шкафлар, өстәл-урындыклар да, картиналар да, кыскасы, нәрсәгә күз төшә – барысы да булдыклы хуҗа кулы белән башкарылган. Идәннән түшәмгә кадәр – һәммәсен кызыксынып карый торган аларда. Эшкә иң беренче булып бәяне, әлбәттә инде, гомер буе шәфкать туташы булып эшләгән хатыны Фәнүзә ханым бирә. Элгәрәк, уллары да кул арасына кергән дә соң, хәзер инде аларның үз тормышлары.

– Ике улым да КХТИ тәмамлады. Агач белән кызыксыну бар үзләрендә. Бигрәк тә уртанчысы Азат бик кызыкты агач эшенә. Зурысы Русланга тимер җене кагылган. Югыйсә, тотынса, теләсә нинди эшкә кулы килә үзенең, – ди әти кеше.

Бу кадәр дә нечкә бизәкләрне уярга аерым эш коралы да кирәктер инде, – дип кызыксынам остадан.

– Монда әллә ни кирәк тә түгел инде, – ди ул тыйнак кына. – Менә бер сынган пычак бар иде, шуны авыш итеп кистем дә... эш коралының шуннан да яхшысы юк...

Сынык булмагае әллә нинди булса да, монда иң мөһиме аның кем кулына эләгүе шул әле...

# Балтачта күпьеллык бәрәңге үстерәләр?!


Автор фотосы

**Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА**

Авылга кайтып җитәргә өлгермәдем – туганым шалтырата:

– Авыл, халык ни эшли, нинди яңалыклар бар?

– Әллә ни юк, бар да йә өй җыештыра, йә бакчада эшли, – дим, үземнең мең дә бер тапкыр дөрес сөйләгәнемә инанып. Ярты көн үттеме, юкмы, хаксызлыгымны аңладым.

## МАЙ – БӘРӘҢГЕ АЛУ ӨЧЕН МЕНӘ ДИГӘН

Күршебез Камилнең бакчада эшләгәнен күреп, үзем дә бераз ял булыр дип, койма буена килсәм, ни күрим... бәрәңге казып ята! Календарьда 1 май ләбаса! Ник берсе өшесен, бәрәңгеләр артык зур булмасалар да, тавык йомыркасы кадәрләре күренгәли.

– Көз көне сез бәрәңге казыганда әйттем ич, мин яз көне казыячакмын дип, менә казыйм, – ди Камил, хәйләкәр генә елмаеп.

– Утыртасың булмас иде, нигә казып торырга. Бәлки чыннан да тишелеп чыгар. Күпьеллык бәрәңге сорты уйлап тапмассыңмы әле, – дидем мин дә.

– Хәзергә җир өстендә калдырып торам, борын чыгарсын, аннан соң утыртам, карарбыз ни булганын.

Бәрәңгеләрне үзебезгә алып кереп пешереп тә карадык. Тәме бераз үзгәрәк, шулай да бал тәме юк, димәк, суык тимәгән. Камил, бәрәңгене алмагачның коелган яфраклары саклагандыр, дигән фикердә.

## ҖӘЙ – СУГЫМ ЧОРЫ

Камилнең бәрәңге казуыннан айнып җитә алмадым, күршебез Раушания, тана суя идек, эчәге карарга булыша алмассыңмы икән, дип кергән. Май аенда мал суябыз диюенә бер гаҗәпләнсәм, «эчәге карарга» диюе бөтенләй таң калдырды. Зур малның эчәгесен бары тик кыш көне салкында гына эшкәртәләр дип күңелгә кереп калган. Малның эчен төшерүгә эчәктәге май шыгырдап ката. Аннан соң бармакларны өшетә-өшетә пычак очы белән сак кына майны аралап аласың. Эчәге эчендәге «матдәләрнең» дә исе һәм рәвеше кышкы салкында ул тикле үк чыдамаслык булмый. Ә монда агач яфрак яра, кошлар сайрый һәм тана эчәгесе. Раушаниянең һәр нәрсәгә үз җавабы.

– Сатарга түгел, үзебез өчен суябыз. Хәзер инде бөтен кешедә зур сандык-суыткычлар тора, саны белән тыгып куйсаң да була, мал сую өчен җәй ни дә, кыш ни, – диде күрше килене, шик-шөбһәләремне таратып.

Итне кая куясыларын аңладым анысы, эчәгесен без карыйсы бит әле. Күңелдән барладым: ун елдан артык эчәге эшкәрткән юк икән инде. Күрше хакы – Алла хакы, ни эшләмәссең. Икенче күршебез Әкълимә апа белән истәлекләрне барлый-барлый зур эшкә тотындык.

– Соңгы елларда терлек эчәгесен эшкәртүчеләр кимеп бара. Әле кайчан гына зур малның эчен эшкәртмәгән гаиләләрне шаккатып сөйлиләр иде, хәзер чистартсалар хәйран калалар, – ди Әкълимә апа.

Ул гомер буе пешекче булып эшләгән кеше, иттарткыч аша чыгарсаң, бик күп төрле ризыклар әзерләп булуын аңлатса да, кызыктыра алмады мине. Әле күптән түгел генә Мөжга шәһәренә барган идек. Үзе пекарня тотучы Гөлфия ханым Хәсәнова, Татарстаннан аермалы буларак, аларда терлек эчәгесен кулланып пешерелә торган камыр ризыкларына өстенлек бирүләре турында сөйләде. Баллы пироглар бөтенләй сатылмый икән.

# Чәк-чәк түгел – бавырсак

## «ШК» журналисты бавырсак пешерергә өйрәнде


Егерме йомыркага пешерелгән бавырсак.


1


2


3


4


5


6


7


8

**Татарстанның Казан тирәсендәге районнарында яшәүче татарлар, гадәттә, чәк-чәк пешерсә, республиканың көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан Әлмәт, Азнакай, Ютазы, Лениногорск, Бөгелмә, Баулы кебек ерак төбәкләрендә туйга килгән кунакларны бавырсак белән каршы алалар. Әйтергә кирәк, әлеге сый Башкортстанда да бик популяр. Бавырсак, чәк-чәк дип тә, төш дип тә атап йөртәләр әле аны. Казан чәк-чәгеннән аермалы буларак, бавырсак эре итеп пешерелә.**

**Зөһрә САДЫЙКОВА,**
Ютазы, Кәрәкәшле

Хәер, авыл җирендә дә бавырсакны бөтен кеше дә пешерә димәс идем. Алар бармак белән генә санарлык була. Шуңа күрә килен төшәсе, бәби кайтасы, аш үткәрәсе булса, шул осталарга заказ бирәләр. Без дә шундый аш-су остасы – Ютазы районының Кәрәкәшле авылында яшәүче Зәрия Хәсәновадан бавырсак пешерергә өйрәнеп кайттык.

### АНЫҢ БАВЫРСАКЛАРЫ УКРАИНАГА КИТӘ

Гомер буе ферма мөдире булып эшләгән ханым лаеклы ялга чыккач, аш-су остасы булып киткән. Әнисе Сөгъдә дә күрше-тирә авылларда уңганлыгы белән дан тоткан.

– Аш-су серләренә кыз чакта ук әнидән өйрәндем. Үзебез өчен гел пешерсәм дә, заказга эшләгәнем булмады. Бу эшне дә кызык итеп кенә башлаган идем, – дип елмая ул үзе. – Халык белеп алды да, менә хәзер бер дә ял юк. Көн дә эшкә барган кебек. Иртән өйдәге, ишегалдындагы эшләрне бер кат бетерәм дә мич янына килеп басам, бишенче яртыда «эштән кайтам». Пешереп тәкъдим итә башлаган елларда кибеткә дә сатуга чыгара идем, хәзер өлгермим, өйгә заказлар күп килә. Читтән дә бик күп киләләр. Украина, Казахстанга да пешереп җибәрдем. Себергә дә күчтәнәч итеп еш алып китәләр. «Безнең туйларга Сөгъдә апа бавырсак пешерә иде, оныкларыбызны синең чәк-чәк белән өйләндерәбез», – дип көләләр кешеләр дә. Яшьрәк вакытта берәр кулинария цехы ачып җибәрәсе калган да ул, анысы турында уйланылмаган шул. Киленемне дә өйрәттем. Хәзер ул да шулай пешереп сата. Көне буе мич янында басып торып сәламәтлек тә бетә, әлбәттә. Билләр, аяклар сызлый, кызган майның күзгә дә зыяны күп. Бабаем да: «Туктат инде бу эшеңне», – ди. Юк, минәйтәм, эшсез ничек яшим инде мин? «Бисмилла»мны әйтеп, эшкә тотынам. Бавырсакларым уңуына сөенәм, йортымнан кеше өзелми.

### ПЕШЕРҮ

Бавырсакны телне йотарлык тәмле, йомшак итүнең беренче шарты: камыр ясар өчен йомыркаларны туңдыргычта (морозильник) катыру.

– Беренчедән, бавырсак пешерү өчен бары тик авыл йомыркасын гына файдаланам. Алар суыткычта бер ай торса, бик сөенәм. Кайвакыт алай булып та бетми, шулай да тиз дигәне дә ике атна тора. Бер туңдырганда йөз данә куям. Туң йомырка сулана, камырга яхшы була. Эш башлауның алдагы көнендә кич белән йомыркаларны туңдыргычтан алып куям. Иртәнгә җылынып тора, – дип аңлатты Зәрия апа.

Кешеләр заказ биргәндә йомырка санына карап яки килограммлап эшләргә куша икән. (Сигез йомыркалысы (1 кг) – 450 сум, утыз йомыркага пешерелгәне (4,5 кг) 3000 сум тора.) Без сигез йомыркага камыр ясадык. Шулай итеп, иң элек сигез йомыркага бер чеметем тоз, бер аш калагы көнбагыш мае, ярты чәй калагы сода салынды. Соданы арттырырга кирәкми, күп булса, бавырсаклар кабармый. Шуннан соң берничә кат иләнгән онны аз-азлап салып агач кашык белән туглыйтуглый камыр изде. Аны бик озак –бер сәгатьләп, ялтыраганчы туглады. Камыр коймак камырыннан – куерак, токмачныкыннан йомшаграк булырга тиеш. (Камырны миксер белән дә болгатып әзерләргә мөмкин. – **Авт.**)

– Сезнең бавырсакларны авыз иткән кешеләр, Зәриянең төше бер ай торса да йоп-йомшак саклана, авызга алгач эреп китә, диләр. Хикмәте нидә соң, Зәрия апа?

– Аның бөтен сере – шушы камырны бер төерен дә калдырмый озак итеп басуда. Камыр озак тугланса, бавырсак йомшак килеп чыга.

Карап торырга гына риза түгел, пешереп тә карыйсым килә, дигәч, Зәрия апа миңа да кабат сигез йомыркага камыр әзерләргә кушты. Бу юлы инде туглавын да үзем тугладым. Йомырка сарысы каты булганлыктан, аны он белән изәизә туглаганда җайлырак. Дөресен әйтергә кирәк, бер сәгать буе камыр туглый-туглый куллар талды. Көненә ничә тапкыр шулай камыр әзерләргә кирәк!

Камыр әзер булгач, аны күз белән якынча чамалап, өч өлешкә бүлгәләде. Һәм бер өлешен аерып алып, онлы тактада әвәли-әвәли озынча «тасма» («бау») сузды. Шуларны 4-5 см озынлыкта кыек итеп кисте.

– Бавырсак пешерергә өйрәнергә теләгән кешеләр дә күп булды. Карап китәләр дә, берәздән: «Зәрия апа, камырын әзерләп була, әмма шуны тәгәрәтеп булмый бит», – дип шалтыраталар, – дип көлә ул.

«Бау»ны мин дә тәгәрәтеп карадым. Чыннан да, читтән карап торганда җиңел кебек тоелса да, йомшак камырны тәгәрәтү ансат булып чыкмады. «Бау»лар киселә торды, газ мичендәге май (1 литр көнбагыш маена 50-100 гр туң май) салынган тимер табакка урнаша торды. Кайнап чыккан майдагы бавырсакларны акрынлап болгата-болгата пешерәсе. Нәзек кенә «тасма»лар 2-3 тапкырга зуррак булып күперде. Шуңа күрә камыр кисәкләрен табакка берьюлы күп итеп салырга кирәкми, алайса алар савытка сыймый башлый. Гомумән, ун йомыркадан да артыгракка камыр изеп булмый. 30 йомыркага бавырсак пешерергә туры килгәндә, өч партиягә бүлеп пешерелә, ди Зәрия апа. Ә бу көне буена җитә дигән сүз.

Шулай итеп, бавырсак пешергәндә искә алынырга тиешле икенче шартны да белеп торырга кирәк. Беренче «бау»дан киселгән бавырсаклар пешеп беткәч, май савытын газ өстеннән алып, салкын урынга суытырга куярга кирәк. Икенче «бау»ны пешерә башлаганчы, суынган майга ярты стакан салкын су салына. Монысы артык кызу майда пешкән бавырсаклар ярылып китмәс өчен эшләнелә икән. Ялгышып, кайнар майга салкын су сала күрмәгез. Табактагы бөтен май тышка чыгып бетәчәк. Күп кеше шуның белән пешә, ди пешекче. Бавырсаклар табактагы майга салынып беткәнче, ут сүрән килеш тора. Аннан соң гына көчәйтелә. Тагын шунысын да искәртте, беренче «бау»ны пешергәндә май бик көйләнеп бетми. Калган «тасма»ларны пешергәндә май күбекләнеп китә, бавырсаклар тагын да ныграк күперә.

Шуннан соң, пешкән бавырсаклар сироп белән баллана. Сироп исә ярты литр суга ике стакан шикәр кушып әзерләнә. Кайнап чыккач, ике аш калагы бал салына.

Телеңне йотарлык бавырсаклар әзер! Чәегез тәмле булсын!

# «Язмышлардан узмыш бармы?»

**Шушы елның 21 апрель кичендә Алексеевск–Чистай арасындагы юлда биш машина бәрелешкән, үлүчеләр дә бар дигән хәбәр интернет челтәре аша бик тиз таралды. Фаҗига урыныннан фотосурәтләр дә урнаштырганнар. Носилкадагы яшь егетнең гәүдәсен күргән кеше: «Йа Аллаһым! Үзең сакла», – дип әйтми калмагандыр.**



Иртәгесен Татарстанның әле бер, әле икенче шәһәреннән туганнарым шалтыратып хәбәр бирде: «Ришат үлгән», «Ришат юл фаҗигасенә юлыккан...» Носилкада ятучы минем ике туган сеңлемнең улы – Ришат Хисамиев булып чыкты.

Бу егетне күргән-белгән кеше: «Сөбханаллаһ, нинди әдәпле бала», – дип әйтми калмый иде. Әйе, әдәплелек, мөлаемлылык, үткен акыл, зирәк зиһен аңа тумыштан ук бирелгән иде.

– Кече яшьтән мәчеткә йөреп, дини белем алды. Биш вакыт намазын калдырмыйча укыды, – ди Алексеевск районы имамы хатибы Рөстәм хәзрәт тә. Аның Ришатка карата әйткән җылы сүзләрен язып бетереп булмый. Ул сүзләр безнең күңелләребезгә әйтерсең нур булып урнаштылар.

–Кайда, кемгә нинди ярдәм кирәк, беренче башлап Ришат оештырып йөрде, ул минем уң кулым иде, – ди хәзрәт.

–Укыганда, ул мәктәпнең күзгесе булды, «5»ле билгеләренә генә укып барды, олимпиадаларда катнашып, һәрвакыт җиңү белән кайта иде, –дип искә ала укытучылары.

Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбен алтын медальгә тәмамлап, КХТИ(У) га укырга кереп, аннан да кызыл диплом алып, өч төрле һөнәргә ия булып чыктылар егетебез. Кем белән генә сөйләшсәк тә, «Ришат белән аралашу үзе бер куанычлы мизгел иде», дип искә алалар. Туганнарым үз улларына һәрвакыт Ришатны үрнәк итеп куйдылар. Кайсы яктан алсаң да, үрнәк булырдай егет иде шул. Түбән Кама шәһәренең "Танэко" заводына эшкә урнашып, анда да тиз арада үз кеше булып алган ул. Аны соңгы юлга озата кайтучылар хисапсыз иде. Әнисе, яшь аралаш: «И улымны бик яратканнар, бик хөрмәт иткәннәр икән», – дип кабатлый. Әтисе улының гәүдәсенә капланып, энекәше Булат кешеләрдән читкә китеп елыйлар. 11 апрельдә 24 яшен генә тутырган иде бит ул. Бу көнне әйтерсең бар табигать елады. Яңгыр яуды да яуды.

«Ни өчен алай, ни өчен болай», – дип әйтергә яратабыз. Сәбәбен Аллаһыбыз бер үзе белә. Бәлки ахирәткә дә фәрештәдәй кешеләр кирәктер?

Ничә тапкыр юл фаҗигасенә дучар булып исән калган, сәламәтлеге нык какшаган сеңлем: «Мин үлгәч, уларым миңа догачылар булырлар дип өметләнә идем, ә киресенчә булып чыкты», – дип өзгәләнә. Язмышлардан узып булмый, күрәсең...

Ришатның әти-әнисен, энесен юатып, җылы сүзләр җиткерәсе килә. Күзнә яшь каплый, тамакка төер утыра. Шушы юлларны укып, алар тынычлансалар иде. Яшәргә көч табып, тигезлекләре белән, исәнлектә-саулыкта, уллары Булатка терәк булып, ә Булат әти-әнисенең ышанычы булып, хәерле, матур гомер кичерсеннәр иде дигән ихлас теләгемне газета аша җиткерәсем килә.

Түбәндәге юлларны улыгызның соңгы сүзләре итеп кабул итегез.

*Аллаһыга сыенып,*
*Тырышыгыз яшәргә.*
*Сезгә калды дөньялыкта*
*Яшен булып яшьнәргә.*
*Чит илләрдән,*
*чит җирләрдән*
*Исән кеше бер кайта.*
*Яшәүнең кадерен*
*белегез*
*Якты дөньяда чакта.*
*Караңгылык төшсә*
*күңегезгә,*
*Мин нур булып*
*кайтырмын.*
*Болыт басса күгегезне,*
*Кояш булып балкырмын.*
*Мине бик сагынганда,*
*Төнге күккә карагыз.*
*Йолдыз булып*
*балкып торыр*
*Сезнең газиз балагыз.*

**Гөлсем ДИМИЕВА,**
Кама Тамагы, Олы Кариле.

# Күзгә алма тәме

**Шәһәр йортларының ишегалды кечкенә генә бер авыл урамы инде ул. Моның шулай икәнен яшь балалы әниләр аеруча яхшы белә. Бер-береңбелән танышасың, аралашасың, белгәнеңне – сөйлисең, белмәгәнеңне – сорыйсың дигәндәй. Аннан соң безне бала үстергәндәге уртак шатлыклар, җиңүләр, вак-төяк мәшәкатьләр дә берләштерә.**

**Зөһрә САДЫЙКОВА**



Сөйләшеп йөри торган кызлар (хатыннар дип бер дә язасы килми бит, әй!) арасында бездән бераз өлкәнрәк Эльвира исемле ханым да бар. Аның кызы да безнекеләр белән бер тирәдә туган. Үзләре башка районда яши, безнең йортта өлкән яшьтәге әнисе торгач, үзе дә шушында үскәч, ишегалдында еш очрашабыз. Эльвира кызын ялгызы үстерә. «Мин авырга калганда, ирем белән рәсми төстә аерылышкан идек инде. Олыгайган көннәремдә ялгыз каласым килмәде. Бала алып кайтырга теләдем... Әтисенең кызы янына килгәне юк. Миңа аның килеп йөрүе дә кирәкми. Болай да бик рәхәт. Шушы баламны алып кайтуым белән дә бик бәхетле мин», – ди ул. Шуннан артыгын безнең – сораган, аның сөйләгәне юк. Шәхси тормыш шуңа да шәхси инде ул. Эльвира – сүз эзләп кесәгә керә торганнардан түгел, уенда – нәрсә, телендә – шул. Авыл апаларына хас нык гәүдәле, җитез. Руль артына утырганына да ун елга якын икән инде. Кызы да, башка балалар белән чагыштырганда, җитезрәк тә, кыюрак та. Баласына яшь ярым булу белән үк шәхси балалар бакчасына урнаштырды да үзе эшкә чыкты Эльвира. Кыскасы, ирем юк, баланы ялгызым үстерәм дип күңел төшереп утырырга вакыты юк аның. Тегендә чаба, монда йөгерә.

Шушы ханымны күргәч, бераз соңлап булса да үзенә иптәшкә бала алып кайтырга уйлаган тагын бер апаны еш искә төшерәм. Кызымны күкрәк астында йөрткән вакытта, 1 нче номерлы бала тудыру йортының йөклелекне саклап калу бүлегендә дәваланып ялырга туры килгән иде. Шул вакытта безнең белән бер палатада Зина исемле ханым да ятты. Аның йөклелек чорының 24-25нче атналары иде. 38 яшьлек ачык йөзле, экчерсез, ягымлы рус апасы белән бер атна эчендә тәмам якынаеп беттек. Кызык-мызык сүзләр сөйләп, гел безнең күңелне күтәрә иде ул. Әнисе, ике ир туганы да бик еш хәлен белешеп тордылар. Дуслары да әледән-әле телефонына шалтырата иделәр. Аралашу вакытында без аның кияүдә түгеллеген аңладык. Хәер, ул үзе дә моны бер дә яшермәде. Беркөнне икәүдән икәү генә калгач, ул үзе турында ачылыбрак китеп сөйләде.

– Бу минем беренче һәм бик тә көтеп алган йөклелегем, – дип сүз башлады ул. – УЗИ малай булачак дип күрсәтте. Исемен дә уйлап куйдык инде. Богдан булачак. Аллаһы Тәгалә биргән бүләк. Чын мәгънәсендә бүләк булачак ул. Кияүгә чыгарга насыйп булмады миңа. Әти-әнием 40 елдан артык бергә яшиләр, бер-берсен ярты сүздән дә аңлыйлар, мин дә аларга һәрчак таяна алам. Туганнарым да минем өчен өзелеп тора. Ләкин беркөнне миңа болар гына аз булуын аңладым. Тормышыма яңа мәгънә салучы, шатлык алып килүче бала кирәк иде миңа. Ләкин теләк кенә аз икән. Берничә кеше белән очрашып карадым, табибларга йөрдем. Тик бәбигә генә уза алмадым. Инде өметем өзелеп барган бер көндә 64 яшьлек ир белән таныштым. Берничә тапкыр очраштык. Юк, гаиләле кеше түгел ул үзе. Хатыны белән аерылышканнар. Аның инде үсеп беткән балалары, оныклары бар. Булачак баламның әтисе нәкъ менә шул кеше булыр дип уйладым! Үзенең әти буласын белгәч, бик нык куркуга калды, әлбәттә. «Минем яшьтә нинди бала багу инде ул!» – диде. Миңа аннан берни дә кирәкми, баламны үзенеке итеп яздыруы да, алименты да, башка төрле ярдәме дә. Ул миңа болай да зур бүләк ясады инде. Үзенә нәкъ шулай дип әйттем дә. Шуннан соң күрешкәнебез дә, аралашканыбыз да юк. Бала тугач, әгәр күрергә теләге булса, каршы килмәячәкмен. Юк икән инде, артыннан да йөрмәячәкмен. Аның каравы әти-әни минем өчен бик сөенде. Бер дә борчылма, баланы да карарга булышырбыз, дип торалар. Менә үзең дә күреп торасың, баламны гына авырлык белән күтәрәм. Авырга калуым да тиз генә булмаган иде, яшем дә үзенекен итә, күрәсең. Монда ятучы кайбер булачак әниләр хастаханәдән тизрәк чыгып китү җаен карый. Ә мин, әгәр табиблар рөхсәт итсә, 40 атнага кадәр сакланырга әзермен. Балам гына вакытында һәм сау-сәламәт туа күрсен.

Мин хастаханәдән өйгә кайтып киткәндә, яңа танышым шунда калган иде. Кызганыч, ни өчендер телефон номерларын алышмаганбыз. Шуңа күрә булачак яшь әнинең дә, дөньяга аваз салырга тиешле бәхет төенчегенең дә алдагы язмышларын белмим. Тик минем аларның барысы да яхшыдыр дип уйлыйсым килә. Башкача мөмкин дә түгел...

# Зөләйха күзләрен ача

**Гүзәл ЯХИНА**

**Флёра ТАРХАНОВА** тәрҗемәсе

→ **Дәвамы.**

Очрашып йөри торган күптәнге хатының була торып, өстәвенә, сиңа ышанып, сине көтеп, килгән саен мендәрләрен кабартып куярга яраткан, күңелен күрер өчен бар нәрсәне дә эшләгән хатын була торып, яңасы турында уйлап йөрү гөнаһ һәм кабахәтлек булмасмы? Уйлый торгач, булмас дип хәл итте. Кайнар хисләр нәкъ менә кеше дөрләп янсын өчен бирелә дә инде. Хисләрең юк икән – бәйләнмә, ялкыны сүнгән, чаткысы беткән кара күмергә ник ябышып ятарга!

Игнатов беркайчан да өстерәлчек булмады. Зифа буйлы, күренекле, тирән фикерле бу иргә хатын-кызлар үзләре күз төшереп, ошарга, күңелен яуларга тырышып йөрделәр. Әмма ул аларның берсе белән дә кушылырга ашыкмады һәм күңелен дә аздырмады. Гомере буе якыннан аралашып йөргән хатыннары (әйтергә дә оят) бер кул бармакларыннан артмады. Ничектер, анда кайгысы юк иде. Унсигезенче елда Кызыл Армиягә язылды да шуннан китте: әүвәл – Гражданнар сугышы, аннары Урта Азиядә басмачыларны кырды... Әгәр Бакиев булмаган булса, бүгенге көнгә кадәр тауларда кылычын болгап йөрер иде, мөгаен. Ул вакытка Бакиев Казанда зур кеше булып өлгерде: чандыр колгасар җирән Мишкадан җитди Тохтамыш Морадовичка әйләнгән иде инде: кырылган пеләш башлы, күкрәк кесәсендә – алтын пенсне. Игнатовны туган Татарстанына ул кайтартты. Ваня, әйдә кайт, диде, миңа монда үз кешеләрем бик кирәк, синнән башка никак, эшләрем бармас. Хәйләкәр төлке, ничек кулга төшерергә белгән. Игнатов бик теләп риза булды, дустына ярдәмләшү өчен туган өенә очып кайтып җитте.

Казан ГПУсындагы эше менә шулай башланып китте. Әллә ни кызыксындырырлык эш булмаса да (кәгазь эшләре, җыелышлар, шуларга охшаш әле тегесе, әле монысы), уфтанып утырып булмый инде... Тиздән Зур Проломная урамындагы кантурда машинистка булып эшләүче кыз белән танышты. Бу кыз башкалардан йомры сөзәк җилкәләре, Илона дигән сәер исеме белән аерылып тора иде. Менә шул чакта, утызы тулган көннәрдә генә Игнатов бер кеше белән озаклап аралашуның шатлыгын тәүге мәртәбә татыды – Илона янына ул инде дүрт ай буе йөри. Гашыйк булды, дип әйтеп булмый анысы. Әмма аның белән аралашу бик рәхәт иде. Ә менә ярату...

Игнатов ул нәрсәне аңламый да иде: ничек инде хатын-кызны яратырга була. Бары тик бөек нәрсәләрне генә ярату мөмкин: революцияне, партияне, үз илеңне. Ә хатын-кызны? Ничек инде шушы үзгә үлчәмдәге зурлыкка мөнәсәбәтеңне бер үк сүз белән белдерергә була? Бу бит, үлчәүнең бер тәлинкәсенә – ниндидер хатынны, ә икенчесенә революцияне куясың, дигән сүз. Ахмаклык түгелме соң бу? Хәтта Настасья да – нинди генә сөйкемле булмасын, барыбер хатын бит инде ул. Аның белән бер-ике төн, күп дигәндә ярты ел булып, ирлек теләгеңне канәгатьләндерү бик җиткән. Ул нинди ярату булсын? Шулай итеп, очрашу — хисләр, эмоцияләр учагы гына. Янса — рәхәт, янып сүнсә, көлен күккә очырасың да тыныч кына яшисең. Шуңа күрә Игнатов үз сөйләмендә «ярату» дигән сүзне кулланмады, кимсетмәде, мәсхәрәләмәде.

Иртән, көтмәгәндә, Бакиев үз янына чакырып алды. Ниһаять, дустым Ваня, чын һәм зур йөкләмәне көтеп алдың, диде. Авылга революция дошманнары белән көрәшергә китәсең. Алар анда шактый әле. Игнатовның шатлыктан йөрәге сикереп куйды: кабат атка, кабат көрәшкә! Аның кул астында эшләр өчен ике кызылармияче һәм мобилизацияләнгәннәр төркеме бирелде. Алар арасында ак толыпта, җирән атта — ул, ул, кадерлем... Язмыш аларны кушар, мөгаен.

Китәр алдыннан Илона янына кереп чыкты, коры гына саубуллашты. Тегесе, аның күзләрендәге салкынлыкны тоеп, шундук елап җибәрде: «Сез мине яратмыйсызмы, Иван?» — диде. Иванның ачуы килде. Теш арасыннан: «Ярату әни белән балалары арасында гына була!» — дип сытып чыгарды да чыгып ычкынды. Ә Илона: «Мин сезне көтәчәкмен, Иван. Ишетәсезме? Көтәчәкмен!» — дип калды аның артыннан. Кыскасы, театр килеп чыкты.

Настасья бөтенләй башка. Ул, кулларын каергалап, беркайчан да көрсенеп утырмас. Ирләргә — хатыннарның, ә хатыннарга ирләрнең нигә кирәклеген бик яхшы белә ул...

Менә бит, яныннан котырып үтеп бара, авызын ерып елмаеп, оялмыйча да туп-туры күзгә карап. Үткен тешләре белән кабартма кулына бияләен тартып кия, назлы бармаклары белән атының ялын сыйпаштыра, учмаланган җирләрен тарата, иркәли.




Игнатовны моңарчы булмаган хисләр биләп алды: тәненең көтелмәгән чымырдавы, баш артыннан башланып, муенына төште, аннан түбәнгә таба китте һәм умырткасы буйлап агып үтте. Күзләрен читкә борды, йөзен чытты: кызылармиячегә постта торганда хатын-кыз турында уйлау килешә торган эш түгел. Ул барыбер аннан беркая да китмәячәк. Атына шпорлары белән төртеп алды да кәрван башына таба чаптырып китте.

* * *

Озак бардылар. Кайчандыр Казан губернасы булган, хәзер Кызыл Татариянең чиксез калкулыклары буйлап акрын гына ак кирмәнле башкалага сузылып барган бүтән кәрваннар койрыгын күреп алдылар. Кемгәдер, бәлки, үзләренең койрыгы да күренеп-күренеп китәдер, тик Игнатов артка каpарга яратмый. Сирәк кенә авыллар аша үтәргә туры килде. Авыл халкы өйләреннән икмәк алып чыгып, кулак дип сөрелгәннәр чанасында башларын иеп, хәсрәтләнеп утыручылар кулына төртте. Игнатов тыймады: ярамаган тагы, Казанда казна ашын азрак ашарлар.

Чираттагы калкулык та (Игнатов инде аларның исәбен югалтты, санамый башлады) артта калды. Кинәт чана табаннарының әчпошыргыч шыгырдавын карачутыр Прокопенконың: «Иптәш Игнатов! Монда!» — дип каты итеп кычкырган тавышы күмде.

Игнатов шундук атын борды: кәрванның тигез тасмасы уртадан өзелгән, әйтерсең лә пычак белән кискәннәр.

Алгы өлеше исә акрын гына алга баруын дәвам итте, ә арткы өлеше басып тора. Атлыларның карачкыл гәүдәләре өзек урында мәш килә, гасабиланып биешә, кулларын болгый.

Игнатов, якынрак килгәч, өзелеп калуның сәбәбен күреп алды: менә ул — яшел күзле хәчтрүш хатын чанасы. Аңа җигелгән ат башын салындырып басып тора, ә корсагы астына колыны кергән дә әнисенең сөтен ашыга-ашыга имеп ята, ыңгырашкалап та ала, нык ачыккан бичаракай. Арттагылар үтеп китә алмый: юл бик тар, бер генә чана сыярлык.

— Байтал нык карыша, — дип, аптырап китеп зарланып куйды Прокопенко, кара кашларын җыерып, өй рәвешенә кертеп. — Мин аны тегеләй дә болай да...

Игнатов атны йөгәненнән тырыша-тырыша тартты, әмма тегесе бирешмәде, башын чайкап, ялларын тузгытты да пошкырып җибәрде — барасы килми.

— Көтәргә кирәк, колынының тамагын туйдырсын инде, — диде акрын гына чанада утырган хатын.

Дилбегә аның итәгендә ята.

— Ирне генә өйдә көтәләр, — диде каты итеп Игнатов. — Ә безгә китәргә кирәк, вакытында барып җитәргә...

Атыннан сикереп төште дә шинель кесәсеннән үз атына дип саклап тоткан, өстенә соры эре тоз сибелгән ипи кайрысын тыңлаусыз шушы ат авызына төртте. Тегесе, ипи кисәген эләктереп алып, авызын шапылдата-шапылдата ашый башлады. Менә шулай, кара аны, башка болай кыланма... Ул атның каты соры йоннар үскән озынча танавын сыйпап торды.

— Назлап иркәләү атны да буйсындыра шул, — диде аның янына килеп җиткән Настасья, матур итеп елмаеп һәм битендәге ике чокырчыгын тагын да тирәнәйтеп.

Игнатов, атны кузгатырга теләп, йөгәненнән тартты: әйдә инде, әйдә, малкай! Ат ипинең авызында калган кисәген чәйнәп йотып җибәрде һәм киреләнеп башын аска иде — бармыйм.

Аны хәзер үк кузгата алмассың, — диде моңарчы дәшми торган аз сүзле Славутский, битендәге озын җәрәхәт эзен ниндидер уй белән ышкып алды. — Колынын туйдырмыйча, беркая да бармас.

— Бармас дисеңме? Алайса... — Игнатов атның йөгәнен әүвәл сузып алды да аннары кискен итеп тартты.

Ат, сары кыек тешләрен ыржайтып һәм тоягы белән бәрә-бәрә, кызгандырып кешнәп җибәрде. Колыны исә, Игнатовка караҗимеш рәвешендәге кара күзләре белән кырын карап, тиз-тиз имүен дәвам итте. Игнатов, кизәнеп торып, атның савырына учы белән каты итеп сугып җибәрде: пшла! Тегесе тагын да көчлерәк кешнәп куйды, башын болгап алды... — барыбер баскан урынында калды. Тагын бер мәртәбә шапылдатып сукты: кузгал, дим! Кузгал! Аның артындагы атлар борчылып, сагайган тавышлар чыгара башлады һәм үрә басты.

— Кузгалмаячак, — дип кабатлады Славутский. — Үтергәнче кыйнасаң да. Монда бөтенләй икенче нәрсә — ана бит ул...

Менә бит ни сөйли, офицер танавы. Кызыл Армиягә качып чыкканына ун ел, ә фикерләве һаман безнеңчә түгел, совет кешесенекенә туры килми.

– Атка мөмкинлек бирергә туры киләме, иптәш Игнатов? — диде Настасья, кашларын күтәреп, үз атын тынычландыру өчен аның муенын сыйпый-сыйпый.

Игнатов, арттан килеп, колынның савырын эләктереп алды да әнисе имчәгеннән аермакчы булды. Тегесе, саранча кебек, аяклары белән тыпырчына башлады һәм тиз генә әнисе корсагы астыннан икенче якка чыкты. Игнатов аркасы белән кар көртенә килеп төште, колын имүен дәвам итте. Настастья, атының йонлач ялына күкрәге белән ятып, шаркылдап көлә башлады. Славутский уңайсызланып борылып куйды.

Игнатов сүгенә-сүгенә торып басты да шлем, шинель, чалбарыннан карны кагып төшерде. Алга киткән чаналарга кулын болгады:

– Тукта-а-а!

Һәм шундук атлылар отряд башына таба элдерттеләр: тукта-а-а. Команда бирелгәнче, ял итегез-е-ез!

Игнатов буденовкасын салды да кызарып чыккан битен сөртеп алды, Зөләйхага усал итеп карап куйды.

– Хәтта атларыгыз сезнең – тулаем контрреволюция!

Кәрван ял итәргә туктады. Колын әнисе сөтен әчеп туйганчы көтәргә туры килә инде...

Кырларга куе зәңгәр эңгер-меңгер таралганда, Казанга кадәр тагын ярты көнлек юл калган иде. Күрше кантонда кунып калырга туры килде.

Җирле авыл Советы рәисе Денисов — тәҗрибәле морякның нык атлап йөреше күзгә күренеп торган киң җилкәле, таза гәүдәле бу ир аларны бик җылы һәм ачык йөз белән каршы алды.

– Сезне кунакханәгә урнаштырам — югары разрядлысына. «Астория»! Ул гына да түгел, тагын да югарырак дәрәҗәлесе бар — «Англетер»! — дип, елмаеп вәгъдә бирде, эре тешләрен күрсәтеп.

→ **Дәвамы бар.**

**Башы 2015 елның декабрь, 2016 елның гыйнвар, февраль, март, апрель саннарында.**

# Сөннәт буенча бүләк бирү кагыйдәләре




**Динебез – игелек, мәрхәмәт, яхшылык дине. Барча кешеләрне ярату һәм бүләк бирү – аның аерылгысыз бер өлеше. Бүләк бирүне безгә Пәйгамбәребез (с.г.с.) сөннәт иткән һәм чын күңелдән бүләк бирүче, һичшиксез, Раббысының рәхмәтенә ирешер. «Бүләк бирегез һәм сезнең арада бер-берегезгә карата ихтирам, хөрмәт, ярату хисе туар», – диелә бер хистә.**

Ислам динендә бүләк бирүнең, бүләкне кабул итүнең билгеле бер әдәпләре һәм кагыйдәләре бар:

**1.** Бүләкне без, Аллаһы ризалыгы өчен дип, мөгамәләләрне ныгыту йөзеннән, тынычлык, ярату һәм дуслык билгесе буларак бирергә тиешбез. Шуңа да бүләкне сайлаганда, яхшы максат күздә тотылырга тиеш, ә кимсетү һәм түбәнсетү түгел.

**2.** Бүләкне башкалардан яшерен бирегез. Чөнки бүләкне кабул итүче аны кайчан һәм кайда ачарга икәнен үзе сайларга тиеш.

**3.** Бүләкне алуга ук аны читкә алып кую ярамый, бу бүләк бирүчене үпкәләтергә мөмкин.

**4.** Бүләк сайлаганда исрафчыл булмагыз, чөнки сез бүләкне кабул итүчене уңайсыз хәлгә куярга мөмкинсез. Шулай ук бүләк сайлаганда бик саран да булмагыз, бу да кешене үпкәләтергә мөмкин. Ләкин бу бүләкнең бәясенә яки күләменә артык игътибар бирегез дигән сүз түгел. Иң мөһиме – ихласлык.

**5.** Әгәр кеше бүләктән баш тартса, ни сәбәпле баш тартуын сорарга һәм алга таба моны күз уңында тотарга кирәк. Әгәр бүләктән баш тарту сәбәпсез икән, моны ачыклап бетерергә һәм билгеле бер килешүгә килү зарур.

**6.** Бүләкне ярату һәм хөрмәт йөзеннән бирергә кирәк, ә үз мәнфәгатьләреңне кайгыртып түгел.

**7.** Үз мәнфәгатьләреңне кайгыртып бирелгән бүләк ул – бүләк түгел, ә ришвәт.

**8.** Бүләк бирүнең максаты тәүбә итү булса, бу да бүләк түгел, ә сәдака була.

**9.** Бүләкне үзегез белгән яхшы күңелле кешеләрдән алу дөресрәк санала.

**10.** Бүләкнең күләме кешене уңайсыз хәлгә куярга тиеш түгел.

**11.** Бирелгән бүләккә ихтирамсызлык күрсәтергә ярамый. Шулай ук бүләк белән мактану да яхшы түгел. Әгәр кеше бүләккә бүләк белән җавап бирә алмаса, ул кеше рәхмәт булса да әйтергә тиешле. Пәйгамбәребез (с.г.с.) әйткән: «Кешеләргә карата рәхмәтле булмаучы, Аллаһының да рәхмәтен алмас».

**12.** Бүләкнең аз яки сыйфатсыз, яки түбән бәяле булуына гына карап, аннан баш тартырга ярамый.

**13.** Бүләктән масаеп баш тартырга ярамый.

**14.** Бүләкне кем аша булса да җибәргәндә, әлеге кешенең аны һичшиксез тиешле кешесенә җиткерәчәген белү зарур. Әлеге кеше ышанычлы булырга тиеш.

**15.** Бүләкне алгач, бүләк бирүче янында әлеге бүләк турында фикер алышу, аның бәясе, күләме, сыйфаты хакында белешү урынсыз.

**16.** Бүләкне икенче берәүгә бирергә мөмкин. Бүләкне тапшыргач, аның хуҗасы әлеге бүләк белән ни теләсә шуны эшли ала.

**17.** Бүләкне кире сорарга ярамый.

**18.** Хәрам бүләк бирү рөхсәт ителми.

**Сәйдә ХӘЯТ.**
(tat.islam-today.ru)

## Намаз вакытлары үзгәрә

Май башыннан (Казан өчен 4 майдан) алып август ае башына кадәр, безнең җирлекнең табигый үзенчәлеге буларак, шәфәкъ аклыгы иртәнге таң белән кушыла. Димәк, төн дәвамында аклык бетми һәм ястү намазының башын, шулай ук иртәнге намазның башын астрономик исәпләү белән билгеләп булмый. Шул сәбәпле, дин галимнәре сүзләренә таянып, бу чорда сәгать белән исәпләүгә күчү карар кылынган. Ястү намазы кояш баегач, 1 сәгать 30 минуттан соң, ә сәхәр тәмамлану һәм иртәнге намаз керү вакыты кояш чыгарга 2 сәгать алдан дип билгеләнгән.

## ТӘРБИЯ СӘГАТЕ

Мөселманның мөселман өстендә алты хакы бар: очрашсаң, сәлам бир; чакырса, бар; нәсыйхәт бирүеңне үтенсә, нәсыйхәт кыл; төчкереп, Аллаһы Тәгаләгә шөкер итсә, җавап бир; авырса, хәлен бел; вафат булса, җеназасын озат.

Нәфесең һәм аны тәрбияли торган кораллар белән сугышырга кирәк. Алар дүртәү: беренчесе – аз ашау, икенчесе – аз йоклау, өченчесе – аз сөйләшү, дүртенчесе – кешеләр тарафыннан күргән зыяннарга каршы сабыр булу.

## СОРАУ-ҖАВАП

**Яңа туган баланың чәчен ничәнче көнендә алалар?**

*Хәнәфи галимнәре, бала тугач, җиденче көндә аның чәчен алуны мәслихәт, диләр һәм әлеге гамәлне эшләргә киңәш итәләр. Әһле-Сөннә (мәлики, шафигый, хәнбәли) мәзһәбләре дә шул ук фикердә тора. Әлеге чәч авырлыгына тиң алтын яки көмешне (яки шушы алтын һәм көмеш бәясенә тиң акчаны) сәдака итеп өләшү дә зарур.*

**Мөселманнарга ат итен ашарга ярыймы? Хәнәфи мәзһәбендә ат итен ашау тыелган дип ишеттем. Әбү Хәнифә (рәхмәтуллаһи галәйһи) үзе нинди фикердә булган?**

*Хәнәфи мәзһәбендә ат итен ашау рөхсәт ителә һәм ул гөнаһ эш саналмый. Ибн Габидинның (рәхмәтуллаһи галәйһи) «Әд-Дөррел-л-мохтар» китабында Әбү Хәнифәнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) үләренә өч көн кала ат итен ашау ярамый дигән фикереннән кире кайтуы турында язылган. Имам Әгъзамның иң мәртәбәле шәкертләре – имам Әбу Йосыф белән имам Мөхәммәд Шәйбанинең (рәхмәтуллаһи галәйһи) шулай ук ат итен ашау хәләл, шәригать тарафыннан тыелмаган дип әйтүе билгеле.*

**Коръән уку алдыннан мөселман кешесе нәрсә эшләсә яхшы була?**

*«Әл-Фәтва әл-Хиндия» китабында, Коръән укырга ниятләгән кеше чиста пакь киемнәр киярга (ир-атларга чалма кию яхшы санала) һәм кыйблага каршы утырырга (бу фикъны һәм Коръәнне ихтирам итү була) кирәк, диелә. Шулай ук бу турыда «Фәтава Кадыхан» китабында да язылган.*

## ГАИЛӘ ДӘРЕСЛӘРЕ




Пәйгамбәребез: «Бер җирдә өч кеше булсагыз, арадан икегез яшерен рәвештә сүз сөйләшмәгез, чөнки бу өченчегезне кайгыга вә шиккә калдырыр. Әгәр дә башка кешеләр өстәлү сәбәпле күбәеп китсәгез, ул вакытта икегезнең генә серләшүегездән зарар юк», – диде.

«Иптәшләрен аерып, икесенең серләшүләре кардәшлек, өлфәт вә күркәм гомер итү әдәпләренә каршы килә. Өченче иптәшләре белми торган тел яки нинди булса да язу ярдәмендә, хәтта ишарәләр белән сөйләшү дә бу тыюга керәдер. Олы мәҗлесләргә җыелган адәмнәрнең дә колактан колакка пышылдашып утырулары, зур эшләр башкаручылар вә серләре бар кебек кыланулары да тәрбиясезлек һәм ваклыктыр».

**Ризаэддин ФӘХРЕДДИН,**
«Җәвамигуль-кәлим-шәрехе»

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА** әзерләде.

# ТЕЛЕМАНЗАРА 

## 9 МАЙ – ДҮШӘМБЕ

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
04:45 «Горячий снег». Художественный фильм (16+)
06:30 «На дорогах войны». Художественный фильм (12+)
08:00 «Баллада о солдате». Художественный фильм (12+)
09:30 Новости Татарстана. Специальный выпуск (12+)
09:40 Парад войск Казанского гарнизона в честь 71-й годовщины победы в Великой Отечественной войне (0+)
11:00 Татарстан хәбәрләре. Махсус чыгарылыш (12+)
11:10 «Молодежь on line» (12+)
12:00 «Горячий снег». Художественный фильм (16+)
14:00 Новости Татарстана. Специальный выпуск (12+)
14:15 «Песни военных лет» (0+)
14:50 «Казань. Бессмертный полк-2016». Прямая трансляция (0+)
16:00 Новости Татарстана. Специальный выпуск (12+)
16:15 Концерт (0+)
17:00 Татарстан хәбәрләре. Махсус чыгарылыш (12+)
17:30 «Мы память в песнях сохраним». Концерт (0+)
18:30 Новости Татарстана. Специальный выпуск (12+)
18:55 «Светлой памяти павших в борьбе против фашизма...» Минута молчания (0+)
19:01 «Белорусский вокзал». Художественный фильм (12+)
20:00 Татарстан хәбәрләре. Махсус чыгарылыш (12+)
20:30 «Белорусский вокзал». Продолжение (12+)
21:30 Новости Татарстана. Специальный выпуск (12+)

### ТНВ-ПЛАНЕТА
06:00 «Хәтер...» Әдәби музыкаль композиция (6+)
07:00 А.Гыйләҗев. «Яра». Түбән Кама татар дәүләт драма театры спектакле (12+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:15 Р.Вәлиева. «Куылган кайгы». Телефильм (6+)
09:30 Бөек Җиңүнең 71 еллыгына багышланган тантаналы хәрби парадтан турыдан-туры трансляция (6+)
10:40 «Сугыш чоры җырлары» (0+)
11:10 «Татарлар» (6+)
11:30 «Халкым минем...» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:15 М.Мәһдиев. «Без – 41нче ел балалары» (0+)
13:05 Р.Харис. «Күзләреңнән үбеп...» С.Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры спектакле (12+)
14:50 «Үлемсез полк-2016». Турыдан-туры трансляция (6+)
16:00 А.Гыйләҗев. «Яра». Түбән Кама татар дәүләт драма театры спектакле (12+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Сугыш чоры җырлары» (0+)
18:55 Фашизмга каршы сугышта һәлак булганнарның якты истәлегенә... Бер минутлык тынлык (6+)
19:00 «Халкым минем...» (12+)
19:30 «Хәтер...» Әдәби музыкаль композиция (6+)
20:05 «Татарлар» (6+)
20:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (6+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)

### РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН
11.00 «Вести-Татарстан». Праздничный выпуск

### ПЕРВЫЙ
5.00, 9.50 Новости
5.10 «День Победы». Праздничный канал
10.00 Москва. Красная площадь. Парад, посвящённый Дню Победы
11.00 Новости с субтитрами
11.15 Х/ф «Диверсант. Конец войны» (16+)
15.00 «Бессмертный полк». Прямой эфир
18.00 Х/ф Премьера. «А зори здесь тихие...» (12+)
21.00 Время

### РОССИЯ 1
5.30, 11.00, 18.00, 20.30, 23.30 Т/с «Истребители» (12+)
7.00 «День Победы». Праздничный канал
10.00 Москва. Красная площадь. Военный парад, посвящённый 71-й годовщине Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.
13.00, 20.00 Вести
15.00 «Бессмертный полк». Шествие в честь 71-й годовщины Великой Победы
22.00 Праздничный салют, посвящённый Дню Победы

### НТВ
4.50 Х/ф «Сочинение ко Дню Победы» (16+)
7.00 «Новое утро». Праздничный выпуск
9.30, 11.00, 19.00 Сегодня
10.00 Москва. Красная площадь. Парад, посвященный Дню Победы
11.15 «Бессмертный полк. Крым». Прямой эфир
12.30 Х/ф «Аты-баты, шли солдаты...» (0+)
14.15 Х/ф «Орден» (12+)
18.00 Д/ф «Севастопольский вальс» (16+)
19.40 Х/ф «Приказано уничтожить! Операция: «Китайская шкатулка» (16+)
23.15 Праздничный концерт ко Дню Победы. Трансляция из Севастополя

### КУЛЬТУРА
7.00 Евроньюс
10.05 «Мгновения Победы»
10.10, 13.25 Юрий Соломин читает стихотворение Константина Симонова «Ты помнишь, Алеша, дороги Смоленщины...»
10.15, 16.50 «Век полета: виражи и судьбы»
10.40 Евгения Симонова читает стихотворение О.Берггольц «Мой дом». Юрий Назаров читает фрагмент поэмы А.Твардовского «Василий Теркин»
10.45 «И все-таки мы победили!» Киноконцерт
11.15 Алексей Петренко читает стихотворение Александра Твардовского «Я убит подо Ржевом»
11.20 Х/ф «Наше сердце»
12.40 Леонид Куравлев читает стихотворение Александра Межирова «Просыпаюсь и курю...»
12.45 Концерт Краснознаменного им. А.В. Александрова ансамбля песни и пляски Советской Армии
13.30 Х/ф «Истребители»
15.00 Василий Лановой читает стихотворения А.Твардовского «Я знаю, никакой моей вины...» и С.Орлова «Его зарыли в шар земной...»
15.05 Д/ф «Ночная ведьма»... Её муж и сыновья...»
15.45 Андрей Ташков читает стихотворение Константина Симонова «Ты говорила мне «люблю»...»
15.50, 1.40 «Священной победе!» Концерт Кубанского казачьего хора
16.45 Гоша Куценко читает стихотворение Константина Ваншенкина «Земли потрескавшейся корка...»
17.15 Александр Домогаров читает стихотворение Юрия Левитанского «Ну что с того, что я там был...»
17.20 Х/ф «Воздушный извозчик»
18.30 Марк Бернес. Любимые песни
18.55 «Светлой памяти павших в борьбе против фашизма»
19.00 Х/ф «Чистое небо»
20.45 Переделкино. Концерт в Доме-музее Булата Окуджавы
22.15 Х/ф «Укрощение огня»

### РЕН ТВ
5.00 Д/ф «Специальный проект с Михаилом Задорновым» (16+)
6.20 М/ф «Как поймать перо Жар-птицы» (0+)
7.40, 21.50 М/ф «Крепость: щитом и мечом» (6+)
9.00, 20.30 М/ф «Иван Царевич и Серый Волк-3» (6+)
10.30 М/ф «Три богатыря и Шамаханская царица» (12+)
12.00 М/ф «Три богатыря на дальних берегах» (6+)
13.15 М/ф «Три богатыря: Ход конем» (6+)
14.40 М/ф «Алеша Попович и Тугарин Змей» (6+)
16.10 М/ф «Илья Муромец и Соловей-Разбойник» (6+)
17.40 М/ф «Добрыня Никитич и Змей Горыныч» (6+)
18.55 «Светлой памяти павших в борьбе против фашизма»
19.00 М/ф «Иван Царевич и Серый Волк-2» (6+)
23.15 Х/ф «Судьба человека» (12+)

### СТС
6.00 «Взвешенные люди» (16+)
8.00 М/с «Фиксики» (0+)
8.30 М/с «Смешарики» (0+)
9.10 М/ф «Шрэк. Страшилки» (6+)
9.35 М/ф «Шевели ластами!» (0+)
10.55 М/ф «Шевели ластами-2» (0+)
12.40 М/ф «Кот в сапогах» (0+)
14.15 М/ф «Шрэк» (6+)
16.00 М/с «Сказки шрэкова болота» (6+)
16.15 М/ф «Шрэк-4» (6+)
16.30 М/ф «Шрэк-2» (6+)
18.20, 19.00 Х/ф «Астерикс и Обеликс против Цезаря» (0+)
18.55 Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания (0+)
20.35 Х/ф «Астерикс и Обеликс: Миссия Клеопатра» (0+)
22.35 Х/ф «Астерикс на Олимпийских играх» (12+)

### МАТЧ ТВ
6.30 Смешанные единоборства. UFC. Трансляция из Нидерландов (16+)
8.45, 9.45, 10.20, 15.05, 23.15 Новости
8.50, 12.40, 23.25 Все на Матч!
9.50 Д/ф «Операция «Динамо» (16+)
10.25 Хоккей. Франция – Словакия. Чемпионат мира. Трансляция из Санкт-Петербурга
13.05 Футбол. «Манчестер Сити» – «Арсенал». Чемпионат Англии
15.10, 18.45, 19.00, 19.40, 22.45 Все на хоккей!
16.10 Хоккей. Чемпионат мира. Россия – Латвия. Прямая трансляция из Москвы
18.55 Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания
19.20 Специальный репортаж (12+)
20.10 Хоккей. Швеция – Чехия. Чемпионат мира. Прямая трансляция из Москвы
0.10 Хоккей. Финляндия – США. Чемпионат мира

## 10 МАЙ – СИШӘМБЕ

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
05:10 «Мәдәният дөньясында» (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Одна ночь любви». Телесериал (12+)
10:00 «Сыргалым». Телесериал (12+)
11:00 «Оныта алмыйм...». Ретро-концерт (0+)
11:30 «Туган җир» (12+)
12:00 «Любовь с оружием». Телесериал (16+)
13:00 «Секреты татарской кухни» (12+)
13:30 «Размышления о вере. Путь к исламу» (6+)
13:35:00 «Не от мира сего...» (12+)
14:00 Новости Татарстана (12+)
14:15 «Музыкаль каймак» (12+)
14:55 «Тиззарядка» (0+)
15:00 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Яшьләр тукталышы» (12+)
15:55 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
16:10 «Мастера» (6+)
16:35 «Һөнәр» (6+)
17:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17:30 «Сыргалым». Телесериал (12+)
18:30 Новости Татарстана (12+)
19:00 «Народный контроль» (12+)
19:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (6+)
20:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
20:30 «Татарлар» (12+)
21:00 «Күчтәнәч» (0+)

### ТНВ-ПЛАНЕТА
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
07:45 «Татар халык җырлары» (0+)
08:15 «Яшьләр тукталышы» (12+)
08:45 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:15 «Башваткыч» (6+)
11:10 «Татарлар» (6+)
11:30 «Туган җир» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Әдәби хәзинә» (6+)
12:45 «Сыргалым-2». Телесериал (12+)
13:30 «Уеннан уймак». Телевизион нәфис фильм. Беренче серия (12+)
14:20 «Мең дә бер җавап» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (6+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Тиззарядка» (0+)
15:20 «Күчтәнәч» (0+)
15:35 «Яшьләр тукталышы» (12+)
16:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
17:30 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Сыргалым-2». Телесериал (12+)
19:10 «Туган җир» (12+)
19:40 «Кичке аш» (6+)
20:05 «Татарлар» (6+)
20:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (6+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)

### РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Рядовые России»
9.25 «Мир культуры»
11.35, 14.30, 17.30, 19.35 «Вести – Татарстан»

### ПЕРВЫЙ
5.00 Телеканал «Доброе утро»
9.00, 3.00 Новости
9.20, 4.30 Контрольная закупка
9.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55, 3.30 Модный приговор
12.00, 15.00 Новости с субтитрами
12.15 «Пусть говорят» (16+)
13.25 «Таблетка» (16+)
13.55, 15.15 «Время покажет» (16+)
16.00 «Мужское / Женское» (16+)
17.00, 2.30, 3.05 «Наедине со всеми» (16+)
18.00 Вечерние новости с субтитрами
18.45 «Давай поженимся!» (16+)
19.50 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым (16+)
21.00 Время

### РОССИЯ 1
5.00, 9.15 Утро России
9.00, 11.00, 14.00, 17.00, 17.50, 20.00 Вести
9.55 «О самом главном»
11.35, 14.30, 17.30, 19.35 Местное время. Вести-Москва
11.55 Т/с «Тайны следствия» (12+)
14.50, 4.45 Вести. Дежурная часть
15.00 Т/с «Верни мою любовь» (12+)
18.15 «Прямой эфир» (16+)
21.30 Евровидение-2016. Международный конкурс исполнителей. 1-й полуфинал. Прямая трансляция из Стокгольма

### НТВ
5.00 Т/с «Супруги» (16+)
6.00 «Новое утро»
9.00 Т/с «Возвращение Мухтара» (16+)
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 Т/с «Москва. Три вокзала» (16+)
12.00 Суд присяжных (16+)
13.20 Обзор. Чрезвычайное происшествие
13.50 «Место встречи»
15.00 Т/с «Отдел 44» (16+)
16.20 Т/с «Улицы разбитых фонарей» (16+)
18.00 «Говорим и показываем» с Леонидом Закошанским (16+)
19.40 Т/с «Законы улиц» (16+)
22.30 «Итоги дня»

### КУЛЬТУРА
6.30 Евроньюс
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры
10.15, 1.40 «Наблюдатель»
11.15, 23.50 Т/с «Коломбо»
12.55 Д/ф «Фасиль-Гебби. Лагерь, застывший в камне»
13.10 Х/ф «Чистое небо»
15.10 Т/с «Петр Первый. Завещание» (16+)
17.05, 22.40 Д/ф «Генрих и Анна. Любовь, изменившая историю»
17.55 Д/ф «Взлетная полоса Владимира Татосова»
18.25 Московский Пасхальный фестиваль. Избранное
19.15 «Спокойной ночи, малыши!»
19.45 «Главная роль»
20.05 Искусственный отбор
20.45 «Правила жизни»
21.15 «Больше, чем любовь»

### РЕН ТВ
5.00, 4.50 «Территория заблуждений» с Игорем Прокопенко (16+)
6.00, 11.00 «Документальный проект» (16+)
7.00 «С бодрым утром!» (16+)
8.30, 12.30, 16.30, 19.30, 23.00 «Новости» (16+)
9.00 «Военная тайна» с Игорем Прокопенко (16+)
12.00, 16.00, 19.00 «Информационная программа 112» (16+)
13.00 Званый ужин (16+)
14.00 Х/ф «Особенности национальной рыбалки» (16+)
17.00, 4.10 «Тайны Чапман» (16+)
18.00, 1.40 «Самые шокирующие гипотезы» (16+)
20.00 Х/ф «Дикий, дикий Вест» (16+)
22.00 «Водить по-русски» (16+)

### СТС
6.00 М/с «Приключения Джеки Чана» (6+)
6.25 М/с «Команда «Мстители» (12+)
6.55 Х/ф «Астерикс на Олимпийских играх» (12+)
9.00 «Ералаш» (0+)
9.30 Х/ф «Астерикс и Обеликс против Цезаря» (0+)
11.30 Х/ф «Астерикс и Обеликс: Миссия Клеопатра» (0+)
13.30, 14.00 М/с «Сказки шрэкова болота» (6+)
13.45 М/ф «Шрэк-4» (6+)
14.10 М/ф «Шрэк третий» (0+)
15.50 М/ф «Шрэк навсегда» (12+)
17.30 Т/с «Кухня» (12+)
20.00 Т/с Премьера! «Беглые родственники» (16+)
21.00 Т/с Премьера! «Пушкин» (16+)

### МАТЧ ТВ
6.30 Д/с «Олимпийский спорт» (12+)
7.00, 9.00, 10.45, 17.30, 23.15 Новости
7.05, 13.00, 23.25 Все на Матч!
9.05 «Твои правила» (12+)
10.00 Д/с «1+1» (16+)
10.50 Х/ф «Макс Шмелинг: Боец Рейха» (16+)
13.30 Смешанные единоборства. UFC. Трансляция из Нидерландов (16+)
14.55 Хоккей. «Звезды Ночной Хоккейной Лиги» – «Сборная Ночной Хоккейной Лиги». Ночная Хоккейная Лига. Гала-матч. Прямая трансляция из Сочи
17.40 Хоккей. Швейцария – Дания. Чемпионат мира. Трансляция из Москвы
19.55, 22.45 Все на хоккей!
20.10 Хоккей. Казахстан – Норвегия. Чемпионат мира. Прямая трансляция из Москвы
0.10 Хоккей. Словакия – Германия. Чемпионат мира. Трансляция из Санкт-Петербурга
2.25 Хоккей. Венгрия – Франция. Чемпионат мира. Трансляция из Санкт-Петербурга
4.40 Чемпионат Европы по водным видам спорта. Трансляция из Великобритании

## 11 МАЙ – ЧӘРШӘМБЕ

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
05:10 «Караоке бәйге» (6+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Одна ночь любви». Телесериал (12+)
10:00 «Сыргалым». Телесериал (12+)
10:55 «Дин вә хәят» (6+)
11:00 «Оныта алмыйм...». Ретро-концерт (0+)
11:30 «Халкым минем...» (12+)
12:00 «Любовь с оружием». Телесериал (16+)
13:00 «Среда обитания» (12+)
13:30 Документальный фильм (12+)
14:00 Новости Татарстана (12+)
14:20 «Каравай» (6+)
14:55 «Тиззарядка» (0+)
15:00 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Без – Тукай оныклары» (0+)
15:45 «Һөнәр» (6+)
16:00 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
16:15 «Приключения Папируса». Мультсериал (0+)
17:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17:30 «Сыргалым». Телесериал (12+)
18:30 Новости Татарстана (12+)
19:00 «Выбери своего кандидата. Теледебаты» (12+)
20:00 Татарстан хәбәрләре (12+)
20:30 «Татарлар» (12+)
21:00 «Күчтәнәч» (0+)
21:15 «Хочу мультфильм!» (0+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вечерняя игра» с Ниязом Игламовым» (12+)
23:00 «Видеоспорт» (12+)
23:30 «Любовь с оружием». Телесериал (16+)
00:20 «Одна ночь любви». Телесериал (12+)
01:15 «Сыргалым». Телесериал (12+)
02:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
03:40 «Халкым минем...» (12+)
04:05 «Яшьләр тукталышы» (12+)
04:30 «Оныта алмыйм...». Ретро-концерт (0+)

### ТНВ-ПЛАНЕТА
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
07:45 «Халкым минем...» (12+)
08:15 «Поем и учим татарский язык» (0+)
08:30 «Һөнәр» (6+)
08:45 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:15 «Яшьләр on-line» (12+)
11:10 «Татарлар» (6+)
11:30 «Яшьләр тукталышы» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Регион» (6+)
12:45 «Сыргалым-2». Телесериал (12+)
13:30 «Уеннан уймак». Телевизион нәфис фильм. Икенче серия (12+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (6+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Тиззарядка» (0+)
15:20 «Күчтәнәч» (0+)
15:35 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:50 «Мең дә бер җавап» (0+)
16:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
17:30 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Сыргалым-2». Телесериал (12+)
19:10 «Регион» (6+)
19:40 «Белем дөньясы» (6+)
20:05 «Татарлар» (6+)
20:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (6+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:45 «Уеннан уймак». Телевизион нәфис фильм. Икенче серия (12+)
23:55 «Дин вә хәят» (6+)
00:00 «Яңалыклар» (12+)
00:15 «Халкым минем...» (12+)
00:40 «Татарлар» (6+)
01:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
02:45 «Нәсыйхәт» (6+)
03:10 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
04:05 «Яшьләр on-line» (12+)
04:55 «Уеннан уймак». Телевизион нәфис фильм. Икенче серия (12+)

### РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
11.35, 14.30, 17.30, 19.35 «Вести – Татарстан»

### ПЕРВЫЙ
5.00 Телеканал «Доброе утро»
9.00, 3.00 Новости
9.20 Контрольная закупка
9.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор
12.00, 15.00 Новости с субтитрами
12.15 «Пусть говорят» (16+)
13.25 «Таблетка» (16+)
13.55, 15.15 «Время покажет» (16+)
16.00 «Мужское / Женское» (16+)
17.00, 2.50, 3.05 «Наедине со всеми» (16+)
18.00 Вечерние новости с субтитрами
18.45 «Давай поженимся!» (16+)
19.50 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым (16+)
21.00 Время
21.35 Т/с Премьера. «Война и мир» (16+)
23.55 «Вечерний Ургант» (16+)
0.30 Ночные новости
0.45 Х/ф «Чак и Ларри: Пожарная свадьба» (16+)
3.50 «Модный приговор»

### РОССИЯ 1
5.00, 9.15 Утро России
9.00, 11.00, 14.00, 17.00, 17.50, 20.00 Вести
9.55 «О самом главном»
11.35, 14.30, 17.30, 19.35 Местное время. Вести-Москва
11.55 Т/с «Тайны следствия» (12+)
14.50, 4.45 Вести. Дежурная часть.
15.00 Т/с «Верни мою любовь» (12+)
18.15 «Прямой эфир» (16+)
21.00 Х/ф «Нелёгкое счастье» (12+)
22.55 Специальный корреспондент (16+)
0.40 Д/ф «Война 2.0. Пиратская версия». «Научные сенсации. Хакеры смерти» (12+)
2.50 Т/с «Срочно в номер. На службе закона» (12+)
3.45 Комната смеха

### НТВ
5.00 Т/с «Супруги» (16+)
6.00 «Новое утро»
9.00 Т/с «Возвращение Мухтара» (16+)
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 Т/с «Москва. Три вокзала» (16+)
12.00 Суд присяжных (16+)
13.20 Обзор. Чрезвычайное происшествие
13.50 «Место встречи»
15.00 Т/с «Отдел 44» (16+)
16.20 Т/с «Улицы разбитых фонарей» (16+)
18.00 «Говорим и показываем» с Леонидом Закошанским (16+)
19.40 Т/с «Законы улиц» (16+)
22.30 «Итоги дня»
22.55 Т/с «Морские дьяволы. Смерч» (16+)
0.50 «Место встречи» (16+)
2.00 Квартирный вопрос (0+)
3.05 Т/с «Дознаватель» (16+)

### КУЛЬТУРА
6.30 Евроньюс
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры
10.15, 1.55 «Наблюдатель»
11.15, 23.50 Т/с «Коломбо»
12.30 Д/ф «Гиппократ»
12.35 «Красуйся, град Петров!»
13.05 Х/ф «Наше сердце»
14.30 Д/ф «Ключ к смыслу. Иван Сеченов»
15.10 Т/с «Петр Первый. Завещание» (16+)
17.05, 22.40 Д/ф «Генрих и Анна. Любовь, изменившая историю»
17.55 Д/с «Пророк в своем отечестве»
18.25 Московский Пасхальный фестиваль. Избранное
19.15 «Спокойной ночи, малыши!»
19.45 «Главная роль»
20.05 «Абсолютный слух»
20.45 «Правила жизни»
21.15, 1.00 «Больше, чем любовь»
21.55 «Власть факта»
23.45 Худсовет
1.40 Д/ф «Древний портовый город Хойан»

### РЕН ТВ
5.00, 4.30 «Территория заблуждений» с Игорем Прокопенко (16+)
6.00, 11.00 «Документальный проект» (16+)
7.00 «С бодрым утром!» (16+)
8.30, 12.30, 16.30, 19.30, 23.00 «Новости» (16+)
9.00 «Военная тайна» с Игорем Прокопенко (16+)
12.00, 16.00, 19.00 «Информационная программа 112» (16+)
13.00 Званый ужин (16+)
14.00 Х/ф «Дикий, дикий Вест» (16+)
17.00, 3.40 «Тайны Чапман» (16+)
18.00, 1.20 «Самые шокирующие гипотезы» (16+)
20.00 Х/ф «Двойной копец» (16+)
22.00 «Смотреть всем!» (16+)
23.25 Х/ф «Герой-одиночка» (16+)
2.00 «Секретные территории» (16+)
2.50 «Странное дело» (16+)

### СТС
6.00 М/с «Приключения Джеки Чана» (6+)
6.25 М/с «Команда «Мстители» (12+)
6.55 М/с «Колобанга. только для пользователей интернета!» (0+)
7.10 М/с «Смешарики» (0+)
7.35 М/с «Фиксики» (0+)
8.05 М/с «Драконы и всадники Олуха» (6+)
9.00 «Ералаш» (0+)
